ЯҢА ЧЫНБАРЛЫК

3D кулланыш, эскәмия дә, реактор да, пилотсыз очкычлар да ясап була

> 2

АРЧА БРЕНДЫ

Табигый күннән тегелгән уңайлы аяк киемнәренә, бизәкле мендәрләргә кызыгучылар күп

> 4

ХАТ ТАШУЧЫ

«Нишлисең инде, почта бик үзгәрде бит хәзер. Бар белгәннәре – товар саттыру...»

> 5

ЯЗУЧЫ ФИКЕРЕ

«Гомергә бер ышанган нәрсәсе түгел иде, әллә нишләп күрәзәчегә барасы итте»

> 8

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 170–171 (29137–29138) | Сишәмбе | 21 ноябрь | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

КАЛАГА ЮЛ – САЛА АША

ЯШЬ ТАБИБЛАРНЫ КИМЕНДӘ БЕР ЕЛ РАЙОНДА ЭШЛӘТӘЧӘКЛӘР

Терапевт, педиатр, ашыгыч ярдәм хезмәте табибы, анестезиолог-реаниматолог, онколог, инфекционист, психиатр һәм патологоанатом... Бүген республиканың сәламәтлек саклау тармагы, барыннан да бигрәк, әнә шул табибларга кытлык кичерә.

Саннар теленә күчерсәк, Татарстанга барлыгы 1300 белгеч җитми. Авырып китәргә дә куркасың. Сырхауханәгә барсаң, көндәлек тормышта гел кирәге чыгып торган әле бер, әле икенче табибның юклыгы ачыклана.

Татарстан Дәүләт Советының Бюджет, салым һәм финанслар буенча комитет утырышында сәламәтлек саклау тармагының үзәгенә үткән әнә шул мәсьәләне күтәрделәр. Татарстан сәламәтлек саклау министры урынбасары Илдар Фатыйхов сүзләренә караганда, бүген республиканың медицина тармагында 14,1 мең табиб хезмәт куя. Быел ун айда республикада 2101 табиб эштән киткән, 2418 белгеч эшкә урнашкан. Килүче белгечләр саны, узган елның шул ук чоры белән чагыштырганда, 316 кешегә күбрәк. Илдар Фатыйхов моның берничә сәбәбен атый.

– Беренчедән, табиблар лаеклы ялга чыгарга ашыкмый. Пенсия яше җитү сәбәпле эштән китүчеләрнең 88 проценты кабат әйләнеп кайта. Яше җитеп, бөтенләй китүчеләр – нибары 168 кеше. Узган ел андыйлар саны 327 кеше иде. Урта медицина хезмәткәрләре арасында да саннар шулайрак, – ди министр урынбасары.

Кадрлар мәсьәләсендә азмы-күпме уңай үзгәрешләр күзәтелүгә республикада яшь белгечләр өчен тудырылган шартлар да этәргеч ясады, дип саный ул. Аларга кызыгып, республикага башка төбәкләрдән дә эшкә килүчеләр бар икән. Билгеле булганча, Татарстанда озак еллардан бирле авыл җиренә эшкә кайткан яшь белгечләр өчен «Авыл табибы» һәм «Авыл фельдшеры» дип исемләнгән дәүләт программалары эшләп килә. Әлеге программалар нигезендә авыл җиренә эшкә кайткан табибларга – 1–1,5 миллион сум, фельдшерларга – 500–750 мең сум акча бирелә. Татарстанда табибларга торак шартларын яхшырту өчен 800 мең сум акча бирүне күздә тоткан грант программасы да гамәлдә. Узган ел әлеге гранттан 1,3 мең табиб файдаланган. Шуларның яртысы – чит төбәкләрдән Татарстанга эшкә килүчеләр.

Табибларга яшәр һәм эшләр өчен нинди генә уңай шартлар тудырылса да, республикада кадрлар кытлыгы әле дә булса саклана бирә. Хәзерге вакытта Татарстанга барлыгы 1,3 мең табиб җитми. Быел министрлык бу мәсьәләне хәл итүнең тагын бер юлын сынап карарга булган. Хәзер укуын тәмамлаган яшь белгеч, каладагы күппрофильле эре дәвалау оешмасына эшкә урнашу өчен, башта район җирендә бер ел эшләргә тиеш.

Яшерен-батырын түгел, озак еллар дәвамында табиб булырга укыган яшь белгеч каланы салага алмаштырырга атлыгып тормый. Максатчан программа буенча укыган яшьләр арасында да үзен укыткан район дәвалау оешмасына кайтып эшләүдән баш тартучылар шактый. Быелдан гамәлгә кергән яңа кагыйдә әнә шул хәлдән чыгуны күздә тота да инде.

Министрлыкта шул рәвешле берочтан район җирлекләрендәге табиблар кытлыгын да киметмәкчеләр. Ник дигәндә, район җиренә эшкә кайткан белгеч, шунда гаилә корып, төпләнеп тә калырга мөмкин бит.

– Югары технологияле медицина ярдәме үзәгендә яшь табиблар күбрәк акча алып эшли, дип уйлаучылар ялгыша. Киресенчә, авыл җирендә эшләүчеләрнеке күбрәк. Беренчел звенода эшләсә, бигрәк тә. Аларга, хезмәт хакыннан тыш, өстәмә акча, социаль түләүләр каралган. Чагыштыру өчен: югары технологияле медицина ярдәме үзәгендә эшләүче яшь табиб бүген уртача 55–60 мең сум хезмәт хакы ала. Район, авыл җирендә эшләүче белгечкә исә уртача 70 мең сум түләнә, – дип сөйләгән иде министр.

Бүген республикага түбәндәге табиблар җитми:
• педиатр (297 белгеч) • терапевт (278 белгеч) • анестезиолог-реаниматолог (150 белгеч) • онколог (118 белгеч) • психиатр (90 белгеч) • инфекционист (64 белгеч) • ашыгыч ярдәм хезмәте табибы (54 белгеч) • патологоанатом (44 белгеч).

Дәүләт Советында узган комитет утырышында республика халкын борчыган тагын бер мәсьәлә күтәрелде. Ул да булса, Татарстанда күзләргә катлаулы операция ясатырлык көчле медицина үзәге булмау. Бүген республика халкы, мондый төр катлаулы операцияне ясату өчен, Чабаксарга барырга мәҗбүр. Илдар Фатыйхов бу уңайдан да тынычландырырга ашыкты.

– Офтальмология хастаханәсен үстерү планда бар. Шунысын төгәл әйтә алам: күзгә планлы операция ясатуга чират кыскара бара. Республика бюджетыннан моның өчен акча бүленә, – дип ачыклык кертте министр урынбасары.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

Министрлыкның – үз планы

Татарстанда министрлыклар ел башыннан барлыгы 9,93 миллиард сум акча эшләгән. Финанс министрлыгы гыйнвар – октябрь чорында халыкка түләүле хезмәтләр күрсәтүдән республика бюджетына алынган керем турында мәгълүмат җиткерде. 2023 елга билгеләнгән план – 11,024 миллиард сум.

Сәламәтлек саклау министрлыгы бу җәһәттән беренче урынга чыккан. Бюджетка ул барлыгы 4,86 миллиард сум акча китергән. Мәгариф министрлыгы (1,47 миллиард сум) – икенче, Мәдәният министрлыгы (1,32 миллиард сум) – өченче. Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы исемлекнең иң ахырына урнашкан: аның кереме бөтенләй юк.

Зарланучылар кимегән

«Безнең ишегалды» программасын тормышка ашыру барышында дүрт елда халыктан барлыгы 48 мең 493 шикаять килгән. «Татарстанда шәһәрләрне үстерү институты» фонды җитәкчесе Наилә Зиннәтуллина әйтүенчә, ел башыннан бирле республикада яшәүчеләр 7342 шикаять юллаган. Узган елдагы белән чагыштырганда, 32 процентка кимрәк сан бу. Сәбәбе берничә. Әйтик, халык белән күзгә-күз очрашулар арткан. «Быел 4 меңнән артыграк очрашу үткәрелде, һәр ишегалды буенча кимендә 3 очрашу уза. Моннан тыш, программаның ничек тормышка ашырылуы матбугатта күрсәтелә», – диде фонд җитәкчесе Хөкүмәт йортында узган утырышта.

Быел шикаятьләрнең 30 проценты юл эшләре сыйфатына бәйле. Наилә Зиннәтуллина сүзләренә караганда, халыктан килгән зарның күбесе урыннарда эшне дөрес оештырмауга: төзелеш чүп-чарына, тавышлы эшләрне иртән башлау, эшне нык сузуга карата канәгатьсезлек белдерүгә барып тоташа.

Проект нәтиҗәсе

Казанда илкүләм проектлар ярдәмендә 4 ел эчендә (2019–2022 елларда) 6 меңләп урынга 27 балалар бакчасы төзелгән. Быел тагын 2 бакча төзелә: берсендә эшләр инде төгәлләнгән, икенчесе 88 процентка әзер. Шәһәр башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Илдар Шакиров әйтүенчә, аларның һәркайсына 220шәр сабыйның йөрүе күздә тотыла.

Аның сүзләренә караганда, башкалабызда «Заманча мәктәп» проекты буенча шулай ук 19 нчы гимназиягә янкорма төзелә. Яңа бинада 300 бала белем алачак. Алар өчен спорт һәм актлар залы, ашханә һәм 12 бүлмә булдырыла. Янкорманы декабрь аенда файдалануга тапшыру күздә тотыла.

Илкүләм проектлар ярдәмендә 4 ел эчендә Казанда барлыгы 10 мең чамасы урынга исәпләнгән җиде мәктәп һәм 300 урынлы бер өстәмә корпус калкып чыккан. Илдар Шакиров искәртеп үткәнчә, «Заманча мәктәп» проекты буенча Казанда уку елы башына 107 нче мәктәп, шулай ук «Салават Күпере», «Светлая Долина» һәм «Кояшлы Шәһәр» торак комплексларындагы уку йортларында өч өстәмә бина төзелгән.

Моннан тыш «Цифрлы мәгариф мохите» проектын гамәлгә ашыру нәтиҗәсендә Казанның сигез мәктәбендә уку җиһазлары яңартылган. Моның өчен 25 миллион сумнан артыграк акча тотылган.

«Киләчәк уеннары – 2024»

Казаннан йолдызларга якынрак

Киләсе елда Татарстан башкаласында узачак «Киләчәк уеннары» халыкара турнирының төп бүләге шәһәрләр буенча сәяхәтен дәвам итә. Узган елларда ул Татарстанда кунак булды. Трофейны Иннополиста, IT паркта каршы алдылар.

Казаннан галәмгә якынрак. Мәгълүм булганча, Уеннарның төп бүләге илнең 7 шәһәрендә булачак, 1 декабрьдә исә Байконур космодромыннан галәмгә җибәреләчәк. Трофей бары тик 2024 елда гына кире Казанга әйләнеп кайтачак.

Күпләр: «Ни өчен трофей?» – дип аптырарга мөмкин. Сорауга җавап бар. «Киләчәк уеннары» проекты җитәкчесе Игорь Столяров аңлатканча, «кубок» сүзе мондый турнирга бик үк туры килми.

– 21 трофей каралган. Ул Уеннарның җиңүчесенә биреләчәк. Галәмдә булып кайтканы исә экспонат буларак Казанда калачак, – диде ул. – Уеннарның төп бүләген трофей дип атарга булдык. Чөнки «кубок» сүзе киберспорт тармагында киң кулланылмый.

«Киләчәк уеннары»нда 100дән артык илнең катнашуын көтәләр. Әлегә 30ы ризалыгын белдергән.

– Бездә җыелма командалар катнашмый. Ярышларда клублар катнашачак. Әлбәттә, бу клублар теге яисә бу илгә беркетелгән булачак. 30 илдән 50ләп клуб инде катнашуын белдерде, – диде Игорь Столяров.

Кибертурнирда киберкуркынычсызлык мәсьәләсе дә бик мөһим. Моңа каршы торырга инде бүгеннән үк әзерләнәләр. Татарстанның дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министры Айрат Хәйруллин сүзләренчә, мәгълүмати куркынычсызлык мәсьәләсе үз эшенең осталарына тапшырылачак.

– Хакерлар һөҗүменә әзерләнәбез, билгеле. Техник мәсьәләләр хәл ителә. Фиджитал уеннарда иң мөһиме нәрсә? Көндәшең кебек уйлый белү. Иминлек мәсьәләсендә дә шулай. «Киләчәк уеннары»нда киберкуркынычсызлыкны профессионаллар кайгыртачак. Аларның тәҗрибәсе зур, – дип ышандырды министр.

Билгеле, киберспорт белән азмы-күпме таныш булганнар (аеруча яшь буын), әлеге халыкара турнирны түземсезлек белән көтә. Айрат Хәйруллин әйтүенчә, тамашачы әле киләсе елда нәрсә буласын күз алдына да китерә алмый.

– Бөтенләй яңа юнәлешне күзәтәчәкбез, яңа тәҗрибә үзләштерәчәкбез. Мондый ярышларны уздыру башка илләрнең дә игътибарын җәлеп итми калмас, – дигән фикердә министр.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

Белешмә өчен

✓«Киләчәк уеннары» халыкара турниры 2024 елның 21 февраленнән 3 мартына кадәр Татарстан башкаласында узачак. Спортчылар башта компьютерда көч сынашса (әйтик, футбол уены), соңрак уен кырына чыгачак һәм туп тибәчәк.
✓Уеннар өчен Казанның барлык зур спорт мәйданчыклары җәлеп ителәчәк. Ярышларның күпчелеге «Казан Экспо» күргәзмәләр үзәгендә узачак.

Сүзгә-сүз

Леонид СЛУЦКИЙ, Дәүләт Думасының Халыкара эшләр комитеты рәисе:

Әти-әни үзара килешә алмаганнан бала зыян күрергә тиеш түгел. Баланы ашатырга да, киендерергә дә, мәктәпкә әзерләргә дә кирәк. Дәүләт бу финансларның ким дигәндә бер өлешен үз өстенә алырга тиеш. Әмма алимент түләмәүче соңыннан бу акчаны бюджетка кире кайтарырга тиеш була.

(«Парламентская газета»дан)

ТАТАРСТАНДА – ЯШЬЛӘР

14–17 яшьлекләр – **462656**

18–24 яшьлекләр – **235966**

25–35 яшьлекләр – **648048**

Барлыгы >> **1046670**

Кыш буранлап килә

Татарстан Гидрометеоүзәге фаразына караганда, киләсе 22–23 ноябрьдә республикада ким дигәндә ярты айлык норма күләмендә явым-төшем көтелә.

Сишәмбе – 21 ноябрьдә көчле кар. Һава температурасы төнлә –2..–7, көндез –3...+1 градус булыр дип фаразлана. Секундына 15–18 метр тизлектә көчле җил, буран чыгачак. Шуңа охшаш һава торышы чәршәмбе – 22 ноябрьдә дә булачак. Юеш кар, урыны белән бозлы яңгыр фаразлыйлар. Секундына 15–20 метр тизлектә көчле җил, буран көтелә. Һава температурасы –1...–6 градус. Пәнҗешәмбе – 23 ноябрьдә көндез –8...–13 градуска кадәр салкынайта. Аз гына кар явачак. Төнлә кар-буран, көчле җил.

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

АРГЕНТИНА – КИСКЕН БОРЫЛЫШ АЛДЫНДА

Дөнья вакыйгалары атнадан-атнага глобаль түнтәрелеш ягына авыша. Жанрның таләбе буенча Израиль – Фәләстыйн иттурагычы киңәергә һәм үсәргә тиеш. Әмма гарәп һәм мөселман илләре конфликтны Фәләстыйн чикләреннән чыгармау өчен тырыша.

Согуд Гарәбстанында, мәсәлән, Газзә сүзен куллану рөхсәт ителми, Фәләстыйнны яклап дога кылу да тыелган. Әле яңа гына анда танылган ислам галимнәренең берсе Халид ибн Фуләйҗ Фәләстыйнны яклаганы өчен кулга алынды. Әмма барыбер төбәктән шомлы хәбәрләр килә. Йәмән гыйсъянчылары Израильнең «Галактика Лидер» корабына һөҗүм итте һәм аны кулга төшерде. Соңыннан корабның катлаулы схемалар аша Япониягә арендага бирелгәне, экипажы да израильлеләр түгел икәне мәгълүм булды. Хәзер япон хөкүмәте экипажны азат итү өчен тырышлык куя. Дүшәмбе иртәсендә Ливан чигендә ике израиль солдатының югалуы турында хәбәр килеп иреште. Искә төшерәбез: 2006 елгы Израиль – «Хизбулла» сугышы солдатлар урлангач башланган иде.

Америкада Байденның рейтингы кискен түбәнәя. Американнар аның сиончыларга ярдәм итүен яратмыйлар. Ләкин Латин Америкасының бер зур гына иле – Аргентина бу атнада АКШ белән якынаю сукмагына басты. Анда якшәмбедә Президент сайлавының икенче туры узды. Лидерлык өчен үтә уң сәясәтче Хавьер Милей белән идарәче партия кандидаты, икътисад министры Серхио Масса бил алышты. Бу юллар язылганда, бюллетеньнәр саналып бетмәсә дә, илне радикаль үзгәрешләр сукмагына алып чыгарга вәгъдә бирүче Хавьер Милейның җиңүе билгеле инде. Аргентинада хәл бик авыр: инфляция 150 процентка якынлашып килә, милли валюта көнләп түгел, сәгатьләп очсызлана, кешеләр иртәдән кичкә кадәр эшләсә дә, тамак туйдырырлык акчага тиенә алмый. Андый вазгыятьтә халык кискен үзгәрешләр вәгъдә итүче радикаль карашлы лидерлар ягына авыша. Уң либертариан карашлы яңа Президент АКШ һәм Израильне яклаячагын, Кытай һәм Россиядән ерагаячагын игълан итеп өлгерде инде. Россиягә каршы санкцияләргә кушылу, Украинаны яклау да – аның планында. Уң либертарианнар дәүләтнең икътисадка һәм җәмгыятькә тыкшынуын кире кага, зур ирекләр вәгъдә итә. Хавьер Милей Аргентина песосын чүплеккә ташларга, илнең Үзәк банкын юк итәргә, долларны ил эчендә бердәнбер валюта итеп кулланырга ниятләвен хакимлеккә килгәнче үк яшерми иде. Аның «Мин дәүләтне дошманым дип саныйм» дигән сүзләре либертариан идеологиясенең асылын чагылдыра. Алдагы дүрт елда аргентиналыларга шундый кискен борылышлар кичерергә туры киләчәк.

Россиядә

НЕФТЬ: БӘЯ ТӨШӘ, ҮЗКЫЙММӘТ ҮСӘ

Үткән атнаның төп икътисад яңалыгы – нефтькә бәя төшә. Brent маркалы нефть 7 июльдән соң беренче тапкыр 77 доллардан түбәнгәрәк тәгәрәде. Россиянең Urals маркасы 65 доллардан арзангарак бәяләнә.

2024 ел өчен бюджетны өченче укылышта кабул иткәндә, казнаның нефть-газ керемнәренә бәйле түгеллеге хакында сүзләр яңгыраса да, углеводород керемнәре бюджетта мөһим урын алып тора. Казнаның өчтән бер өлешен шулар тутыра. Гадәттә «кара алтын» очсызланганда, башка чималлар да арзаная. Шуңа күрә алдагы елда керемнәр 29 процентка үсәчәк дип ният ителсә дә, кәгазьгә язганның чынга ашуы факт түгел. Әмма пенсияләр һәм хезмәт хаклары индексацияләнәчәк. Бюджеттагылар, әйтик, хезмәт хакларының 9,8 процентка үсүенә өметләнә ала. Хезмәткә түләүнең минималь күләме 18,5 процентка үсәчәк. Ләкин реаль үсешнең күпме буласын инфляцияне алып ташлагач кына белү мөмкин.

Россия өчен тагын бер мөһим нәрсә бар: «кара алтын»ның үзкыйммәте арта. Быелның өченче кварталында беренче квартал белән чагыштырганда үсеш 74 процент булган. Бу – Росстат игълан иткән рәсми сан. Бер тонна нефть чыгару өчен бүген 31326 сум 50 тиен акча кирәк. Беренче кварталда бу сан – 17939 сум 30 тиен генә, икенче кварталда 21470 сум 50 тиен булган. Үзкыйммәт мондый темплар белән үссә, нефтьтән акча керәме-юкмы бит әле. 2012 елдан соң үзкыйммәт уртача өч тапкыр арткан, дип раслый рәсми мәгълүматлар. Үзкыйммәтнең үсешен товарга бәя күтәреп компенсациялиләр. Тышкы базарда бәяләр үсми, киресенчә, түбәнәя. 2014 елгы кризис алдыннан баррель, әйтик, 100 доллардан шактый югары иде. ОПЕК+нең «кара алтын» чыгаруны байтак чикләвенә карамастан, быел бәяләр күзгә күренерлек түбән. Үзкыйммәтнең артуын мотор ягулыгына бәя күтәреп капларга туры киләчәк, ди «Российская газета». Дөрес, үзкыйммәттә төп урыннарның берсен файдалы казылмаларга салым (НДПИ) алып тора. Бюджетка акча кирәк булгач, хөкүмәт ул салымны даими рәвештә колагыннан тартып үстерә. Автор тоннаны баррельгә әйләндереп, нефтьнең агымдагы бәясенә тапкырлады. Россия нефтенең бер тоннасы бүген 42 мең сумга якын акча бирә. Үзкыйммәтне алып ташлагач, 11 мең сум тирәсе акча кала. Нефтьне транспортлау бәясе күпмегә төшүен белмибез. «Кара алтын» чыгаручылар кулында акча бик әллә ни калмавын чамалап була.

РӘИС КӨНДӘЛЕГЕ

ЯҢА ЧЫНБАРЛЫК

tatarstan.ru

3D графикасын кулланып, эскәмия дә, реактор да, пилотсыз очкычлар да ясап була. Моның мөмкин хәл икәнен Казанда узган «Аддитив технологияләр» лидер-форумында исбатладылар. Кызыклы, ә иң мөһиме сәнәгатьтә дә кулланырга мөмкин булган эшләнмәләр белән Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов та танышты.

Казанның «Мавыктыргыч фән һәм техника йорты» оешмасы Zenit 3D принтерын кулланып эш итә. Оешма вәкиле Алинә Гыйльметдинова сөйләвенчә, мондый ысул ярдәмендә нәрсә генә эшләмиләр. Бетон, пластик, сумала, керамика һәм башка төр материаллардан файдаланалар. Коронавирус чорында, 3D принтер кулланып, табиблар өчен махсус саклагычлар бастырганнар.

CubicPrints компаниясе җитәкчесе Роман Архангельский күргәзмәгә аддитив технология кулланып ясалган… эскәмия алып килгән! Аңа утырып та була.

– Күптән түгел парклар өчен шундый эскәмияләр эшли башладык. Менә әле Краснодар крае белән хезмәттәшлек итәргә җыенабыз. Көненә 2 эскәмия чыгара алабыз. Принтер үзе барысын да эшли, коры катнашманы болгата, – диде ул.

Форум ачылышында Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов та булды, күргәзмә эше белән танышты.

Татарстан өчен мондый технологияләр ят түгел. Рөстәм Миңнеханов сүзләренчә, аддитив технологияләр үсеше өчен республикада көчле сәнәгый, фәнни-мәгариф һәм технологик нигез бар.

– Сәнәгать һәм авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерү күләме буенча Татарстан Идел буе федераль округы төбәкләре арасында – беренче, ил буенча бишенче урында тора. Чикләүләргә карамастан, республика икътисады үсеш күрсәтте, – дип тә өстәде Рәис.

Татарстан Рәисе искәрткәнчә, аддитив технологияләр инде хәзердән үк көнкүрешебезгә, төрле тармакларга ныклап кереп бара.

– Әлеге технологияләр әзер эшләнмәләрнең сыйфатын яхшыртырга гына түгел, яңа ысул белән тагын да яхшыракларын җитештерергә ярдәм итә, – диде республика Рәисе. Аның сүзләренчә, 2030 елга бөтен дөнья продукциясенең 2/3 өлешен аддитив технологияләр кулланып ясалган детальләр тәшкил итәчәк.

– Татарстан аддитив продукцияне кулланучы булырга гына түгел, төп мәсьәләләрдә хәлиткеч рольне уйнарга да әзер, – дип искәртте Рөстәм Миңнеханов.

Белешмә өчен

- Әлеге форум бишенче мәртәбә уза. Бу чара 3D кулланып бастыру юнәлеше буенча фикер алышу, индустрия яңалыклары белән танышу мәйданчыгы булып тора. Биредә тармак белгечләрен, дәүләт оешмаларын, инстиутларын, фән, бизнес вәкилләрен җыялар.
- Ике көнлек форум кысасында авиация, атом сәнәгате, автомобиль төзелеше, медицина, төзелеш өлкәләрендә аддитив технологияләрне куллану алымнары турында сөйләшәчәкләр.
- Сан теленә күчсәк, чарада 2500дән артык кеше катнашыр дип көтелә. Форумда 120ләп предприятие, илнең 15 югары уку йорты тәкъдим ителгән, күргәзмә мәйданчыгы 500 квадрат метр урынны били. 60 спикер чыгышы көтелә.

СЫНАЛГАН ХЕЗМӘТТӘШЛЕК

Татарстан Хөкүмәте йортында Кытайның Shanghai Launch Automotive Technology компаниясе белән хезмәттәшлек турында сөйләштеләр. Рөстәм Миңнеханов компания вице-президенты Цзянь Цзе җитәкчелегендәге делегация белән очрашты. Launch – Кытайдагы бәйсез транспорт инжиниринг оешмаларының берсе.

Татарстан Рәисе очрашуда республиканың Кытай компанияләре белән якыннан хезмәттәшлек иткәнен, узган ел ике арадагы товар әйләнешенең 58 процентка артып, 1,6 миллиард долларга җиткәнен әйтте. Күрсәткечләр быел да арта. «Кытай бизнесы Татарстанда зур эш алып бара. Уртак эш өчен юнәлешләр күп. Сезнең компания белән дә хезмәттәшлек итү кызыксындыра», – диде Рөстәм Миңнеханов.

Кытай белән хезмәттәшлекне киңәйтү турында «Бердәм Россия» – «Кытай Коммунистлар партиясе» диалогы утырышында да фикер алыштылар. Анда Татарстан Дәүләт Советы Рәисе, «Бердәм Россия» партиясенең Югары Советы әгъзасы, партиянең Татарстандагы бүлеге Секретаре Фәрит Мөхәммәтшин катнашты. Утырышта ул партия оешмаларының Россия белән Кытай арасында төбәкара хезмәттәшлекне үстерүдә мөһим роль уйнавын әйтте. «Бүгенге дискуссия, дөньяда көн кадагына суга торган мәсьәләләр буенча, Россия һәм Кытайның төп сәяси көчләренең тоткан урыны буенча ачыктан-ачык фикер алышу ил лидерлары арасындагы үзара килешенүләрне партия, төбәкләр мәсьәләләре белән баета», – диде ул.

Дәүләт Советы Рәисе Россия белән Кытай арасындагы күпкырлы хезмәттәшлектә төбәкләр, партияләр арасындагы элемтәләрне ныгыту буенча Татарстан тәҗрибәсен билгеләп үтте.

Парламент башлыгы әйтүенчә, Татарстанның Кытай провинцияләре белән хезмәттәшлеге көчәйде. Узган атнада Татарстан Рәисе, «Бердәм Россия» партиясенең Югары Советы Бюросы әгъзасы Рөстәм Миңнеханов Шэньчжэнь шәһәренә сәфәр кылды, югары технологияләр күргәзмәсендә һәм кайбер алдынгы предприятиеләрдә булды, провинция җитәкчелеге белән очрашты. 2014 елдан бирле Россиянең Сәүдә вәкиллегендә Татарстанның сәүдә-икътисадый вәкиле, ә 2015 елдан бирле Казанда Кытайның Генераль консуллыгы эшләп килә. Республикабызда Кытайдан 2 меңгә якын студент белем ала. Кытай инвесторлары республикада үзләренең проектларын гамәлгә ашыра.

Фәрит Мөхәммәтшин быел Казанда «РОСТКИ: Россия һәм Кытай – үзара файдалы хезмәттәшлек» халыкара форумы узганын да искә төшерде. «Без анда ышанычлы бик күп дуслар таптык», – диде ул.

Стратегик диалог кысасында шулай ук 2024–2026 елларга Россия һәм Кытайның төп сәяси көчләренең алга таба хезмәттәшлеге турында беркетмә имзаланды.

Көчле рухлы булды

Кемерово өлкәсенең элеккеге губернаторы Аман Тулеев вафат. Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов мәрхүмнең якыннарына һәм төбәк башлыгына кайгы уртаклашу телеграммасын юллады.

«Ирегез Аман-Гельды Молдагазыевич Тулеевның вафаты сәбәпле, кайгы уртаклашуны кабул итегез. Бик көчле төбәк җитәкчеләре исәбенә кергән, күп елларга Кемерово өлкәсенең сәнәгате үсеше юнәлешен һәм йөзен билгеләгән фидакарь кеше арабыздан мәңгегә китте. Аман-Гельды Молдагазыевич тугрылыклы тарафдарларының, күпсанлы коллегаларының хәтеренә үзенчәлекле шәхес, талантлы җитәкче, Кузбасс халкы арасында зур абруй яулаган һәм ил җитәкчелегенең аерым ышанычын казанган күренекле дәүләт эшлеклесе, сәясәтче буларак кереп калачак.

Кайгыгызны уртаклашам, бу авыр көннәрдә ныклык һәм түземлек телим. Шулай ук улыгыз Дмитрий Амановичка, мәрхүмнең барлык туганнары һәм якыннарына кайгы уртаклашуны тапшыруыгызны сорыйм. Иң кадерле кешегезнең якты истәлеге, эчкерсез мәхәббәтегез гаиләгезгә бу авыр кайгыны кичерергә ярдәм итсен», – диелә мәрхүмнең хатыны Эльвира Тулеева исеменә юлланган телеграммада.

«Иң тәҗрибәле, абруйлы төбәк җитәкчеләреннән берсе булган Аман-Гельды Молдагазыевичның тормыш һәм хезмәт юлы бик зур хезмәт сөю үрнәгенә әйләнде, ә инде күмер чыгаручы төбәкнең, анда яшәүчеләрнең тормышын төрле яклап үстерү аның эшендә иң мөһим бурычка әйләнде. Кузбасста яшәүчеләр алдында яулаган абруе, шулай ук ил җитәкчелегенең ышанычын казануы аның яңаны булдыру юлындагы күпьеллык хезмәте нәтиҗәләре һәм Кемеровоның социаль-икътисадый өлкәсенә зур өлеш кертүе турында сөйли. Аман-Гельды Молдагазыевичның халык хәтеренә Россиянең чын мәгънәсендә ватанпәрвәре, үзен тулысынча туып-үскән иленә һәм анда яшәүчеләргә хезмәт итүгә багышлаган фидакарь, көчле рухлы кеше буларак кереп калачагына иманым камил. Татарстанда яшәүчеләр исеменнән һәм шәхсән үз исемемнән Кемеровода яшәүчеләрнең барчасының кайгысын уртаклашам», – диелә өлкә губернаторы Сергей Цивилев исеменә юлланган телеграммада.

Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин парламент депутатлары исеменнән Аман Тулеевның гаиләсе һәм коллегаларының, Кемеровода яшәүчеләрнең кайгысын уртаклашты. «Кемерово өлкәсен, гомумән, Россия Федерациясен үстерүгә үзеннән зур өлеш керткән күренекле дәүләт һәм җәмәгать эшлеклесе арабыздан мәңгегә китте. Ул абруйлы сәясәтче, дәүләт бурычларын үтәү буенча зур тәҗрибә туплаган җитәкче иде. Төбәктә социаль-икътисадый һәм иҗтимагый-сәяси вазгыятьне тотрыкландыруга юнәлдерелгән бик күп эшләрне башлап йөрүче булды», – диелә Сергей Цивилев исеменә юлланган телеграммада.

АРТСА ДА, КИМЕГӘН

КОММУНАЛЬ ХЕЗМӘТ КҮРСӘТҮЧЕЛӘР ТАРИФЛАРНЫ КҮТӘРЕРГӘ ТӘКЪДИМ ИТТЕ

Халык түли, ә җылылык белән тәэмин итүче оешмалар тиешле акчаны алып бетерми. Алай гына да түгел, зыян күләме дистәләгән миллион сум белән исәпләнә. Җылылык кая китә? Татарстан Дәүләт Советында узган комитет утырышында әнә шул сорауга җавап эзләделәр.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Парламентта Торак сәясәте һәм инфраструктура үсеше комитеты утырышы үтте. Баш бәласенә әверелгән мәсьәләне «Чистай җылылык челтәре предприятиесе» җитәкчесе Марат Харисов күтәрде. Аның сүзләренә караганда, соңгы берничә елда гына да оешма җылылык белән тәэмин итүдә 29 миллион сумлык зыян күргән. Акча кайнар суга «ага», дип тә фаразлады ул. Баксаң, тотылган кайнар су белән аны җылытуга киткән чыгымнар туры килми икән.

– 2017 елның 1 гыйнварыннан бирле кайнар су белән тәэмин итү өчен суны җылытуга тотылган энергия нормативлары күпфатирлы йортларда урнаштырылган гомуми исәпләгечләр белән тәңгәлләштерелми, – дип ачыклык кертте Марат Харисов.

Аның әйтүенчә, коммуналь хезмәтләр күрсәтүчеләрнең керемнәре белән чыгымнары туры килмәвенә фатир хуҗаларының юыну бүлмәсендә сөлге киптерү өчен хезмәт иткән кайнар су торбасын үзгәртеп коруы да сәбәпче булырга мөмкин. Мәсәлән, әлеге торба аша идәнне җылыта алалар. Кайнар су акмый, ә җылылык энергиясе сарыф ителә.

– Бер кубометр суны җылытуга киткән энергия күләме шәхси җылыту пунктлары булган йортларда да тиешле нормативтан күбрәк. Бу исә икътисадый югалтуларга китерә. Әлеге хәл Түбән Камада да, Бөгелмәдә дә күзәтелә. Зыян күләме бик зур. Мәсьәләне ничек хәл итәргә? Нормативларны яңадан карарга, ә шәхси җылыту пунктлары булган йортларда өстәмә исәпләгечләр урнаштырырга кирәк, – дип тәкъдим итте утырышта катнашкан «Татэнерго» генераль директоры урынбасары Рим Галиәхмәтов.

Фатирда су торбасын рөхсәтсез үзгәртеп тоташтыруга чик куярга кирәклеген депутатлар да инкарь итмәде. Өйдә юыну бүлмәсендәге торбаны, гомумән, алып атучылар, балконны бүлмәгә кушып, аны җылытучылар да җитәрлек бит.

– Халык ни теләсә шуны эшли, – диде комитет вәкиле Андрей Егоров. – Бу мәсьәләдә катгый закон булырга тиеш.

Комитет җитәкчесе Александр Тыгин әйтүенчә, әлеге мәсьәлә республикадагы барлык коммуналь предприятиеләргә диярлек кагыла.

– Исәпләгечләр йортка фәлән кубометр кайнар су, фәлән гигакалория җылылык килгән дип исәпли. Җылылык белән тәэмин итүчеләр исә сумнарда моннан азрак ала. Фатир хуҗалары азрак түләми, исәп-хисап шулай оештырылган. Шуңа күрә коммуналь хезмәтләр күрсәтүчеләр финанс елы азагында банкротлыкка чыкмабызмы дип борчыла, – диде ул.

«Җылылык кая китә?» дигән сорауга җавапны да, бәя күтәрүдән бигрәк, чимал белән тәэмин итү челтәрендәге торбаларның искерүеннән башларга киңәш итте ул. Кайнар торба буйлап намуссыз милек хуҗаларына кадәр да барып җитәргә мөмкиннәр.

Эльвира ВӘЛИЕВА

Ватан хакына

КӘГАЗЬ ТҮГЕЛ, ГАМӘЛ БЕЛӘН!

Зөлфия Хәлиуллина

Моннан ике ай элек Менделеевск районының Ижевка мәктәбенә хәрби операциядән кайткан 28 яшьлек Минтимер Әхмәтҗановны директор итеп куйганнар. Аның белән укучыларда ватанпәрвәрлек хисе тәрбияләү турында сөйләштек.

Мәктәптә бүген 89 укучы белем ала. Менделеевск районының мәгариф идарәсе башлыгы Рәис Нәҗипов белдергәнчә, Минтимер – алар өчен зур табыш. Ул кәгазь эше белән генә патриотик тәрбия алып барам, дип йөрүчеләрдән түгел. Ватанпәрвәрлек хисен булдыру өчен яңа алымнар эзләргә дә кирәкми, ди. Телевидениедән бүгенге заман геройларын карарга, тарих белән кызыксынырга кирәк.

– Элеккеге директор гаилә хәле буенча эштән киткәч, җәй буе аның урынына белгеч эзләдем. Газетага белдерүләр бирдем, кая гына мөрәҗәгать итмәдем. Шуннан соң бу вазыйфага Минтимерне билгеләдек. Исеме дә Минтимер, үзе дә тимер кебек, – ди Рәис Нәҗипов, егетне мактап.

– Мәктәп директорларын җыеп: «Мөхәммәт Мәһдиевнең «Фронтовиклар» романын бер көн эчендә укып чыккан идем. Безгә Ватанны саклаганда яраланган, анда катнашып, медальләр алган фронтовик эшкә килде», – дип таныштырдым. Мондый укытучыны башка күргән юк. Нинди мөмкинлегебез бар, бергәләп ярдәм итик, дидем. Район укытучылары ай саен бер көнлек хезмәт хакын хәрби операциягә ярдәм итеп күчерә.

Минтимер мәктәпкә килгәндә, укыту эшләре буенча урынбасар, пешекче, савыт-саба юучы да булмаган. Ике көн эчендә барысын да тапкан ул. Укучылар да, укытучылар да үзен бик җылы кабул иткән. Мәгариф башлыгы, бар эшне ялт итеп башкара, дип мактады.

Сүз уңаеннан, район башлыгы Радмир Беляев, «Аммоний» җәмгыяте белән берлектә «Яшь укытучы», «Яңа директор» гранты булдырганнар. Проектларны уңышлы яклаучылар арасында Минтимер Әхмәтҗанов та бар. Аңа 200 мең сумлык сертификат тапшырылган.

Ижевкага юл уңаеннан Бәзәкә мәктәбенә сугылдык. Анда Минтимернең әнисе Тамара пешекче булып эшли икән. Моңа кадәр Менделеевскида яшәп, 7 ел элек Бәзәкәгә күченгәннәр. Ул – мәрхүм әтисе Мансур абыйның туган авылы. Әнисе рус милләтеннән булса да, Минтимер татарча аңлый, күпмедер дәрәҗәдә сөйләшә дә белә.

– Өч бала тәрбияләдек. Минтимер – төпчеге. Улымны хәрби операциягә җибәрү бик авыр булса да, борчылуымны башкаларга күрсәтмәдем. Минтимергә һәрвакыт: «Синең белән горурланам», – дидем. Кечкенәдән балаларны, гадел һәм игелекле булыгыз, дип үстердек. Менә шушы ике сыйфатны каннарына сеңдердек. Катгый таләпләр куймадык. Минтимер белән сердәшләр без, бер-беребездән бер нәрсәне дә яшермибез. Ул бик нечкә күңелле, – ди Тамара ханым.

Улының кечкенә чагын да искә төшерде ул. Минтимер 4 яшьтә үк укырга өйрәнгән икән. Бакчага баргач, сабыйларга китаплар укыган. Тәрбияче Лариса Владимировна: «Ул – минем булышчым. Минтимер укый, ә балалар тыңлый», – ди торган булган.

Минтимер Чаллы автомеханик техникумын, КФУның Алабуга институтындагы инженерлык-технология юнәлешен тәмамлаган. Техникумда – мастер, шул ук вакытта автомәктәптә дә эшләгән ул. Узган ел октябрь аенда повестка килгән. Гаилә башлыгының сүзе бер була: «Китәм».

– Донецк Республикасының Угледар юнәлешендә хезмәт иттем. Беребез дә кире чигенмәдек. Барыбыз да җиңүгә ышандык. Кызганыч, февральдә сул аягым яраланды. Мәскәү табиблары ядрә кыйпылчыкларын алды. Җиде ай буе госпитальдә дәваландым. Аксаклап йөрдем. Мине яуга кире җибәрмәделәр. Нишләтәсең, шулай туры килде. Яудагы иптәшләремне онытмыйм, алар белән аралашып торам, – дип сөйләде Минтимер Әхмәтҗанов. – Өйгә кайткач, нәрсә белән шөгыльләним икән, дип озак уйландым. Бәхеткә, газетада директор кирәк, дигән белдерү күрдем. Тормышымны мәктәп белән бәйләвемә үкенмим. Кыенлыклар бар, әмма яңа эшкә өйрәнеп киләм. Безне авырлыклар, киресенчә, чыныктыра гына.

Минтимер үзен геройга санамаса да, укучылары аны шулай дип йөртә. Балаларны көчле рухлы, физик яктан нык, ватанпәрвәр итеп тәрбияләргә тырыша ул. Мәктәптә спорт түгәрәге алып бара. Укучылары белән төрле чараларда катнаша. Тик аларга фронттагы хәлләр турында сөйләми.

– Быел директорның тәрбия эшләре буенча киңәшчесе вазыйфасы булдырылды. Без яшь, энергияле Алексей Самаринны билгеләдек. Аның белән хәрби операциягә багышланган махсус почмак эшләдек. Хәрби музейны җиһазладык. Балалар белән бергәләп гуманитар ярдәм җыябыз. Клубка маскировка челтәре үрергә йөрибез. Бу эшне оештырган Фәнисә Нургалиевага рәхмәт, – ди директор.

Минтимер әйтүенчә, халык битараф түгел. Фронттагы хәлләрне сораша, барысы да булышырга әзер. Ул үзе дә финанс ярдәме күрсәтә икән. Тик бу хакта безгә берни дә әйтмәде. Авыл җирлеге башлыгы Роза Мәсәгутова гына серне чиште: «Арабызда Минтимер кебек олы йөрәкле, ярдәмчел кеше булуына бик сөенәбез. Акчалата булыша, ярдәмне илтеп тапшыра. Аны барыбыз да хөрмәт итә».

Сәрия МИФТАХОВА

БЕРЛӘШҮ

Биектау районының Дөбьяз авылы халкы махсус хәрби операциядәге егетләргә кулдан килгәннең барысын да эшләргә тырыша. Тәм-том да җыялар, җылы киемнәр дә тегәләр, маскировка челтәрләре дә үрәләр. Бер ел эчендә күбесе туганлашып, якын кешеләргә әйләнгәннәр. Барысын да бер хәсрәт берләштерә – уллары, ирләре яу кырында аларның. Әлфия Камалованың улы да, өлешчә мобилизация башлануга, махсус хәрби операциягә әләгә.

– Улым контракт буенча Самарада хезмәт итә иде. Өлешчә мобилизация башлангач, беренче көннәрдә үк илне сакларга китте. Ул чакта бик авыр иде. Хәбәр килмәгән көннәрдә телефонны кулыма тотып йоклыйм. Әз генә тавыш булса да, уянам. Ир-ат шалтыратса, ни әйтер икән, дип куркып торам. Улым өчен бик борчылдым. Бер ай ярымнан соң гына элемтәгә чыга алды. Алгы сызыкта булган, – дип сөйли Әлфия апа. – Олы улым да, энем янына барам, диде. Шуны белдем дә авылдашларыма хәбәр юлладым. Кем ничек ярдәм итә ала, балаларга булышыйк әле, дидем. Иртән хәбәр иттем, кичке 8дә инде күмәчкә кадәр пешереп китерделәр. Улым белән мин дә юлга кузгалдым.

Әлфия апа, юлда барганда ашау-эчү онытылды, ди. Гомере буе тарих укыткач, башка шәһәрләрне күзәтеп барган. Һәр җирдә гыйбадәтханәләр эшләп тора икән. Аллаһы Тәгаләгә ышанучы халык яши икән дип тынычландым, ди ул.

– Икенче көнгә барып җиттек. Улым белән очрашып, иптәш егетләренә алып килгән күчтәнәчләрне тапшырдык. Сөенде балалар. Улыма безнең яныбызда калырга да мөмкинлек бар иде. Тик ул ризалашмады. Егетләрне ташламыйм, диде. Горурландым шул сүзләрен ишеткәч. Горурланырлык бит! Ул – минем 3 яшьлек чагында тәрбиягә алган балам. Туганымның сабые. Әнисе туры юлга кермәсме, әтисе пәйда булмасмы, әби-бабай үзенә алмасмы дип көттем. Тик булмады. Улым үземә насыйп булган икән, – ди Әлфия апа. – Бик акыллы булып үсте. Батыр булды. Гел биеклектән сикерер иде. Курку белмәде. Махсус хәрби операциядән август аенда ялга кайтты. 4 медале бар, күрәсең, кыю булган. Тагын китмәкче иде, Казан танк училищесына укырга керергә тәкъдим иткәннәр. Имтиханнарын тапшырып керә алды.

Әлфия апа улы янына баргач, андагы халыкның кешелеклелегенә сокланган. Кибетләрдә сатучылар, улларыгыз өчен борчылмагыз, без аларны ташламыйбыз, дигәннәр. Кайчак 4–5 егетегезне бирегез, өебездә кунак итәрбез, мунча кертербез, дип тә киләләр, ди. Җылы аш белән сыйлап, юындырып, киемнәрен юып бирүчеләр дә күп икән. Әле менә бер егет кибеткә кирәк-яракка кергән булган. Сатучы кибетен япкан да теге егетне өенә алып кайткан. Бик күп ризык, яшелчәләр биреп җибәргән.

– Үзенең баласы махсус хәрби операциядә булган аналарны яхшы аңлыйм мин. Әнә шуңа да, 20 авыл берләшеп, егетләргә ярдәм җыябыз. Авыл халкы бик бердәм. Кышын кар да бирмәс бу, дигән кешеләр, киң күңелләләнеп, әллә ниләр китерә. Төрле яклап сыналдык. Мәрхәмәтле, изге җаннар күп икәнен аңладык. Олы яшьтәгеләр дә, авырып торучылар да ничек тә булышмакчы була. Халык бик бердәм. Безнең Дөбьяз халкына чиксез рәхмәтлемен. Кавал мәктәбе дә, безнең мәктәп тә, балалар бакчасы коллективлары да бу эшкә кушылды. Бик бердәм эшлибез, – ди Әлфия апа. – Егетләрнең иң күп сораган әйбере – маскировка челтәре. Әнә шуңа да аны үрә башладык. Кемдер ярдәм итә, кайберәүләр акчалата булыша. Материалы да бик кирәк. Үреп бетергәч, апалар аларны дога укып, төреп куя. Хәзер эченә хатлар язып салабыз. Үзебез догада торабыз. Егетләрнең исәнлеген сорап, 70 мең тәһлил чыктык. Доганың көче зур! Улым да, үлем белән янәшә йөргәндә, укыган догаларымның коткаруын әйтә. Аллаһы Тәгалә балаларыбызны саклап йөртсә иде. Илләр тизрәк тынычлансын иде, дип телибез. Җир йөзендәге һәр ананың теләгедер бу. Әтиләрен өзелеп көтүче сабыйлар, ирләрен көтүче хатыннар бар. Барысына да очрашулар насыйп булса иде.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

ТАШЛАМАЛАР һәм ГАРАНТИЯЛӘР HEROES.TATAR 117

- РОССИЯ ОБОРОНА МИНИСТРЛЫГЫ ХИСАБЫНА ТУПЛАНМА-ИПОТЕКА СИСТЕМАСЫ АША ТИЗ АРАДА ТОРАК САТЫП АЛУ МӨМКИНЛЕГЕ
- ХЕЗМӘТ УРЫНЫННАН ТОРАК ЯКИ ТОРАКНЫ НАЙМГА АЛЫП ТОРГАН ӨЧЕН КОМПЕНСАЦИЯ
- ХӘРБИ-МЕДИЦИНА УЧРЕЖДЕНИЕЛӘРЕНДӘ БУШЛАЙ ТИКШЕРЕНҮ, ДӘВАЛАНУ ҺӘМ РЕАБИЛИТАЦИЯ УЗУ
- ФЕДЕРАЛЬ БЮДЖЕТ ХИСАБЫНА ГОМЕРНЕ ҺӘМ СӘЛАМӘТЛЕКНЕ ИМИНИЯТЛӘШТЕРҮ
- 20 ЕЛ ХЕЗМӘТ ИТКӘННӘН СОҢ ТАШЛАМАЛЫ ПЕНСИЯ АЛУ ХОКУКЛАРЫ
- ХӘРБИ ХӘРӘКӘТЛӘР ВЕТЕРАНЫ СТАТУСЫ ҺӘМ ТИЕШЛЕ ТАШЛАМАЛАР
- КРЕДИТ ҺӘМ САЛЫМ КАНИКУЛЛАРЫ
- БАЛАЛАРНЫ ВУЗДА БУШЛАЙ УКЫТУ
- БАЛАЛАРГА ҖӘЙГЕ САВЫКТЫРУ ЛАГЕРЬЛАРЫНДА БУШЛАЙ ЯЛ
- КОНТРАКТ БУЕНЧА ХЕЗМӘТ ИТҮЧЕ ХӘРБИ ХЕЗМӘТКӘРЛӘРГӘ РОССИЯ ФЕДЕРАЦИЯСЕ СУБЪЕКТЛАРЫННАН БЕРДӘМ ӨСТӘМӘ ТҮЛӘҮЛӘР, ТАШЛАМАЛАР ҺӘМ ГАРАНТИЯЛӘР



Ил ташламас

Рәхмәтле ял

Өйдә тыныч булсын! Махсус хәрби операциядә катнашучы егетләргә якыннарының тормыш мәшәкате алдында ялгыз калмавын белү кирәк. Моның өчен районнарда ниләр эшлиләр?

Азнакай

Азнакайда махсус хәрби операциядә катнашучы егетләрнең гаиләләре игътибарсыз калмый. Район башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Дамир Гыйләҗев әнә шулай ди. Барысының да хәлләрен белеп, булышып торалар.

– Махсус операциягә киткән егетләр гаиләләренең һәрберсенә җаваплы кеше беркеттек. Үзем дә 4 гаиләнең хәлләрен белешеп торам, – ди Дамир Гыйләҗев. – Батыр егетләр үстергән ата-анага кулдан килгәнчә ярдәм итәбез. Әле менә шушы көннәрдә бер егетебезнең әтисенә медицина ярдәме кирәк булды. Табибларга йөртеп, хастаханәгә салдык. Хәзер бар да яхшы.

Азнакай районы башлыгы Марсель Шәйдуллин исә, ялга кайткан егетләр белән очрашып, хәлләрен белешә һәм истәлеккә махсус эшләткән сәгать бүләк итә.

– Егетләрнең барысы да безгә кадерле. Гаиләләре дә күз уңында. Әйтик, әтиләре хәрби операциядә булган балалар бушлай туклана, түгәрәккә йөргән өчен дә акча түләмиләр. Сабыйларның күңелен күрер өчен кулдан килгәнне эшлибез, – ди Дамир Гыйләҗев. – Өйләнмәгән ир-атларның әти-әниләренә ярдәм итәбез. Утын сораучыларга алып кайтып, кисеп, ярып, өеп бирәбез. Аларга мәктәп укучылары да ярдәм итә. Егетләрнең әти-әниләрен, гаиләләрен районга килгән җырчыларның концертларына да чакырабыз. Күңелсезләнеп утырмасыннар, кеше арасына чыгып, кәефләре күтәрелсен, дибез.

Менделеевск

Һәркемгә үзенеке кадерле. Берәү дә чит түгел. Менделеевск район аппараты җитәкчесе Ришат Нәфыйков шулай ди. Алар район халкы ярдәме белән егетләргә кирәк-ярак җыюны дәвам иттерә.

– Авылларда маскировка челтәрләре үрәләр. Коры ашлар әзерли башладык. Окоп шәмнәре ясауны да туктатмыйбыз. Көннәр салкынайткач, җылы кием-салым тегәләр, оекбашлар бәйлиләр. Соңгы вакытта бездә «коры душ» ясый башладылар, – ди Ришат Нәфыйков.

Менделеевскида да ялга кайткан егетләр район башлыгы янына рәхмәт әйтергә килә. Ярдәм сораучылар кимеде, ди Ришат Нәфыйков.

– Ул гаиләләргә кулдан килгәнчә ярдәм итәбез. Нинди генә сорау белән килсәләр дә, булышу юлларын табабыз, – ди ул. – Махсус хәрби операциядәге егетләргә исемле посылкалар җибәрәбез. Ватан сагында торган егетләрне үстергән әти-әниләренә рәхмәтлебез.

Мамадыш

Мамадыш егетләре район башлыгы Анатолий Иванов белән күрешмичә юлга кузгалмый. Ялга кайткан һәр ир-ат, җитәкчеләр белән сөйләшеп, кирәк икән, гозерен җиткерә.

Махсус хәрби операция башланганнан бирле Мамадыш районы егетләргә 37 тапкыр гуманитар ярдәм җибәргән. 178 тоннадан артык күчтәнәч дигән сүз бу. Ватан сагында торучы егетләр өчен ярты ел эчендә 7 мунча гына ясап җибәргәннәр. Лисичанск шәһәрендә яшәүчеләргә, махсус хәрби операциядә катнашучы егетләрнең гаиләләренә 42 миллион сумнан артык ярдәм җыелган.

– Районның һәр авыл җирлеге, бик тырышып, егетләр өчен кирәк-ярак әзерли. Берәүләр тегә, икенчеләр бәйли. Чәкчәк пешереп җибәрүчеләр дә бар. Аны бигрәк тә яраталар, – ди волонтер Фәнил Гыйззәтуллин. – Әле менә үзем казылык ясаткан идем. Якташларга аннан да өлеш чыгардым. Сагыналар инде алар да. Туган якларында җитештергән тәмле ризыкларны алып барбыз. Мамадыш лимонадын да үз итәләр. Шоколадка кадәр алып барабыз. Тепловизор, квадрокоптер, машина да илттек. Кыскасы, егетләр нәрсә сорый – шуны табарга тырышабыз. Егетләр монда аларны көтүебезне, алар өчен барысына да әзер булуыбызны белеп торырга тиеш. Ныклы тыл барын белү егетләрне көчле итә. Тагын бер теләк: ярдәм итәм дип янып йөрүчеләр кимемәсен иде. Әгәр шушы яхшы теләк белән яшисең икән, бар да әйбәт булачак.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

Белдерү

Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан капиталь төзелеш объектларының кадастр бәяләве нәтиҗәләрен раслау турында, шулай ук кадастр бәясен билгеләгәндә җибәрелгән хаталарны төзәтү турында гаризаларны карап тикшерү тәртибе хакында хәбәрнамә

«Дәүләт кадастр бәяләве турында» 3 июль, 2016 ел, № 237-ФЗ Федераль закон, Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының 09.11.2023 ел, № 3140-р боерыгы нигезендә, Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан капиталь төзелеш объектларының дәүләт кадастр бәяләве нәтиҗәләре расланды.

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының 09.11.2023 ел, № 3140-р боерыгы Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2023 елның 17 ноябрендә (№ 11628) теркәлде.

Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан капиталь төзелеш объектларының кадастр бәяләве нәтиҗәләре белән Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының рәсми сайтында (https://mzio.tatarstan.ru) танышырга мөмкин.

Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан капиталь төзелеш объектларының дәүләт кадастр бәяләве буенча хисап материаллары «Дәүләт кадастр бәяләве үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе сайтына урнаштырылган.

Кадастр бәясен билгеләгәндә җибәрелгән хаталарны төзәтү турында гаризаларны карап тикшерү тәртибе «Дәүләт кадастр бәяләве турында» 3 июль, 2016 ел, № 237-ФЗ Федераль законның 21 статьясы нигезендә билгеләнгән.

ИЛШАТ НУРИЕВ:

«БЕЗДӘ ТЫРЫШ ХАЛЫК ЯШИ»

Әдәбиятка биргән мәшһүр шәхесләре белән генә түгел, тырыш халкы белән дә данлыклы бу район. Авыл хуҗалыгы ягыннан да алдынгыларның берсе ул. Сүзебез – Тукай Ватаны – Арча районы турында. Район бүген ничек яши? Халкынниләр борчый? «ВТ» хәбәрчесе Арча районы башлыгы Илшат НУРИЕВ белән шул хакта сөйләште.

tatar-inform.ru

:: Сөйләшүебезне сөенечле вакыйгадан башлыйсы килә. Күптән түгел сезнең район муниципаль берәмлекләре арасында узган бәйгедә «Татарстан Республикасының мәдәни башкаласы» дигән дәрәҗәле исемгә лаек булды. Нинди хисләр кичерәсез? Моңа ничек ирештегез?

– Бөтен команда, халыкның бердәм булып эшләве нәтиҗәсе бу. Бүген безнең һәр авыл җирлегендә бик күп мәдәни чаралар үтә. Һәр авыл җирлеге башлыгы: «Бездә тырыш халык яши», – дип горурланып әйтә ала. Бу, дөрестән дә, шулай. Арча гомер-гомергә Казан арты төбәге дип йөртелә. Халкыбызның бик күп алдынгы карашлы кешеләре, байлары, зыялылары шушы яклардан, танылган язучыларыбыз гына да йөздән артык. Шәхесләребезне дә кушып санасаң, аларның саны 300дән арта. Бездә тормыш дәрәҗәсе югары дибез икән, бу халкыбызның булдыклы, укымышлы, бердәм булуы белән бәйле дип уйлыйм. Ә инде республикабызның мәдәни башкаласы дип танылуга килгәндә, без җиңүне сорап йөрмәдек, куанычлы хәбәрне соңгы көнне генә ишеттек. Бу бәйгедә гран-при алуыбызны бөтен район халкына бирелгән бик зур бәя, дәрәҗә дип саныйм. Хәзер инде шушы дәрәҗәне югары тотарга да кирәк.

:: Арчага турист буларак кайткан кеше нәрсәләрне күреп китәргә тиеш?

– Без Яңа Кырлай авылын бик зур парк дәрәҗәсенә җиткереп, үстерергә җыенабыз. Ниятләрне тормышка ашыра башладык инде. Хәзерге вакытта анда күлләр чистартыла, яңа басмалар, яңа парк, язучылар аллеясы, яңа тротуарлар пәйда булачак. Районга эшлекле сәфәренең берсендә Рәисебез: «Һәр татар Кырлайда булып кайтырга тиеш», – дигән иде. Кырлай музей комплексы бүген дә уңышлы гына эшләп килә. Анда ял итә торган урыннар да бар. Арчаның үзендә дә музейлар бик күп. Татарстандагы берданбер Әлифба музее да бездә эшләп килә. Арчаның «Казан арты», әдәбият музейлары да бик яхшы эшли. Авылларда да музейларыбыз бик күп. Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы татар телен саклау һәм үстерү мәсьәләләре комиссиясе җитәкчесе, якташыбыз Әхмәтов Марат Готыф улы ярдәме белән Курсави укыткан мәдрәсәне төзекләндереп, анда да музей ачарга җыенабыз. Шәһәребез кечкенә генә булса да, бар нәрсә сыйган. Бик матур стадионыбыз, аның янында Казансу паркыбыз бар. Шәһәрнең үзендә генә дә, тулы бер программа төзеп, көн буе йөреп чыгарлык матур урыннарыбыз күп. Тамак ялгап чыгарга хәләл кафе да, ресторан да бар. Читтән килүчеләр өчен кунакханәләр эшли.

:: Шулай да шәхсән үзегез районга туристларны җәлеп итү дәрәҗәсеннән канәгатьме?

– Кызганыч, канәгать түгел. Әлегә глэмпинг юнәлешендә эшләргә эшмәкәрләр таба алмыйбыз. Районга кунакка килгән кешеләр өчен кызыклы маршрутларны ишәйтергә кирәк. Эшләгән эшләребез дә шактый. Безнең Яңа Кырлай авылында Кыш бабай резиденциясе бар. Районга килгән туристлар саны ике тапкыр артты. Мин эшкә килгән генә чорда Арчага елына 25 мең чамасы турист килә иде, хәзер ул 60 меңгә җитте. Ашыйм дигән кешегә, әйткәнемчә, тамак ялгар урыннар да, кунып китәр җирләр дә бар. Үз чиратыбызда районыбызда яшәүче халкыбызга да яшәр өчен барлык мөмкинлекләрне дә эшләргә тырышабыз. Менә шуны эшләр идем дип зурдан кубып әйтерлек эш тә юк хәзер, дөресен әйткәндә. Кәче авылына күпер, Күпербаш, Кылачы, Урта Сәрдә, Өчиле авылларына юл саласы бар. Берничә авылга мәдәният йорты кирәк. Дөрес, алар янәшәсендәге авылларда клублар эшли үзе. Халкыбызга, яшьләргә мөмкинлекләр тудырылып тора. Тик туристлар өчен бөтен шартлар бар дип мактана алмыйбыз әлегә. Шул ук Тукайның туган җире – Кушлавыч авылына да туристлар аз килә әле.

:: Сез үзегез дә – хакимияткә эшмәкәрлек тармагыннан килгән кеше. Районда эшмәкәрлек үсеше өчен җитәрлек шартлар тудыра аласызмы?

– Шартлар начар димәс идем. Бүген эшлим дигән кешегә нинди генә программа, нинди генә грантлар юк. Күптән түгел сәнәгать паркы булдырдык. Анда алты резидентыбыз эшли. Әмма районыбызның бер бәласе бар – без Казанга якын. Шул сәбәпле, азрак күзе ачык кеше Казанга китәргә тырыша. Үз хезмәте белән калада күбрәк акча эшли ала бит ул.

:: Авыл хуҗалыгы районы дисәк тә, Арча – барыбер шәһәр. Җитештерү предприятиеләре бүген ни хәлдә?

– Әйткәнемчә, күптән түгел ачылган сәнәгать паркында алты резидент эшли. Анда Россия буенча иң яхшы комбиазык заводларының берсен ачтык. Шунда ук балалар ризыклары әзерли торган оешма да эшләп килә. Күптән түгел алар сафына торт пешерүче инвесторыбыз да кушылды. Бүген анда эш гөрли. Сәнәгать паркына тагын өч резидент кушылырга җыена. Әмма бу мәсьәләдә бер проблема бар. Районыбызда, кызганыч, эшче куллар җитешми. Кая барма: «Ник эш урыннары булдырмыйсыз?» – дип сорыйлар. Булдыргач, эшләргә кешебез юк. Бүген районда йөк бушатучыдан башлап, сатучы, хисапчы, юристка кадәр – барысы да кирәк. Табибларга да кытлык. Бу яктан, кызганыч, «кызыл зона»да йөрибез. Районда уртача хезмәт хакы – 43 мең сум чамасы.

:: Арча – авыл хуҗалыгы буенча алдынгы районнарның берсе. Быелгы кырыс шартлар нинди нәтиҗәләр бирде?

– Ашлык күләме буенча беренче өчлектән төшкән юк, быел да өченче урында булдык. 160 мең тонна ашлык җыеп ала алдык. Узган ел 220 мең тонна җыеп, беренче урында идек. Игенчелек буенча начар эшләмибез. Республикадагы иң яхшы терлекчелек комплексларының берсе – безнең «Яңарыш» агрофирмасында. Анда әле генә бөтенроссия семинары уздырдык. «Северный» агрофирмасында да республикадагы иң зур сөт комплексларының берсен салырга җыенабыз. Терлек азыгы әзерләү буенча да начар эшләмәдек быел, тиешле күләмдә сыйфатлы азык әзерли алдык. «Казанка» агрофирмасында 300 баш терлеккә исәпләнгән комплекс салынды. Шәхси хуҗалыкларда да маллар саны ул кадәр кимемәде. Малларын бетерүчеләр моның сәбәбен сөт бәясе төшү белән аңлата. Аннары авыл халкы да картая бит. Яшьләр китә, өлкәннәр сыер асрый алмый. Һәр нәрсә шул башкалага якын булуга барып тоташа.

– Арчага чит төбәкләрдән күчеп килүчеләр күпме?

– Күп дип әйтерлек булмаса да, бар. Бөгелмәдән, Лениногорскидан күчеп килгән гаиләләрне беләм. Безнең районны, яшәү өчен уңайлы, диючеләр арта барыр дип уйлыйм.

– Сез тыелган челтәрдә халык белән даими рәвештә туры эфирлар уздырдыгыз. Ул яктан иң ачык район башлыкларының берсе идегез. Соңгы вакытта андый аралашуларыгыз нинди форматка күчте?

– «ВКонтакте» челтәрендә дә еш язалар. Аларның барысын да үзем укып барам һәм халык соравын, халык үтенечен җаваплы кешеләргә юллыйм. Кешенең бер генә гозере дә игътибарсыз калмый.

– Ун елга якын шушы вазыйфада эшлисез. Нәрсә өчен рәхмәт сүзләре ишетәсез?

– Кайбер кеше үзенең проблемасын хәл иткән өчен рәхмәт әйтә. Авылларыбызга салдырылган социаль әһәмиятле биналар, юллар өчен рәхмәт әйтүчеләр дә бар. Әйтмәүчеләр дә очрый. Бөтен кешегә дә ярап бетеп булмый бит инде ул… Кешене игътибар белән тыңлап, җавабыңны бирергә кирәк. Ярдәм сорап килгән бер кешене дә кире борып җибәргәнем юк. Барысын да тыңларга, аңларга тырышам.

:: Сезнең белән шактый катлаулы вазгыятьтә очраштык. Махсус хәрби операциядә катнашучыларга ярдәм сездә ничек оештырылган? Нинди өстәмә ярдәм чаралары бар?

– 200дән артыграк егетебез мобилизация һәм контракт буенча махсус хәрби операциядә катнаша. Һәр гаилә белән элемтәдә торырга тырышабыз. Авыл җирлеге башлыгыннан тыш, һәр гаиләгә администрациядән берәр хезмәткәр яки депутат җаваплы итеп куелган. 32 гаилә шәхсән үземнең карамакта. Мин алар белән һәрдаим элемтәдә торам. Сораулар туса, хәл итәргә тырышам. Нинди ярдәм кирәк булса, кулдан килгәнчә булышырга тырышабыз. Егетләргә гуманитар ярдәм җыю эше дә яхшы оештырылган. Булышабыз дип торган аерым оешмаларыбызның күп булуы бик мөһим һәм шатлыклы.

Мирасыбыз

«ИТЕК, ЧИТЕК, ЭНӘ, БЕЗ... ЙӨЗ»

Мондый сынамыш, күрәсең, Арча ягында тугандыр. Төрле районнарда яшәүче танышлардан сораштырдым. Алар: «Никтер, ишеткән юк», – диделәр. Ә без аны балачакта такмаклап-такмаклап әйтә идек. Шуңа күрә «итек, читек» сүзләре кергән санамышның нәкъ бездә, Казан арты районнарында тууы табигый, дигәнрәк уйлар күңелгә керде дә инде.

Чөнки XIX гасыр ахыры, XX гасыр башында Арча, Әтнә, Биектау районнарында читекләр, чүәкләр тегү бик таралган була. Ул һөнәр тора-бара сәнгать дәрәҗәсенә күтәрелә. Күптән түгел Яңа Кырлайдагы Тукай музеенда Күн мозаикасы сәнгатенә багышланган «Безнең мирас» күргәзмәсе ачылды.

Ни өчен нәкъ менә Кырлайда? Музейга чагыштырмача яңа гына директор итеп билгеләнгән Алинә Мөхәммәтшина, телефоннан шалтыратып, мине Кырлайга дәшкәндә: «Гади генә күргәзмә түгел ул, Риман абый, килгәч, үзең барын да күрерсең, күңелең кузгалмый калмас», – дигән иде. Кузгалды шул күңел, Алинә сеңлем. Арча читекләренең даны бөтен дөньяга таралган чак безнең яшьлек елларына туры килде. Әле телевидениедә эшләгән чагымда ук командировкага берәр районга барсам, Арчадан икәнемне белүгә, миңа чүәкчитеккә заказ бирә башлыйлар иде. Размерларын язып, акчасын биреп куялар иде. Шулай итеп, Риман абыегыз сәүдәгәрлеккә кереп китә язды. Даны югары, тарихы зур иде Арча читекләренең, Кырлай музеена килгәч, бу тарихны яңадан искә төшерделәр.

1929 елда Татарстанда күн аяк киемнәре тегү буенча кооператив артельләр төзелә, бишесе – Казанда, алтынчысы – Арча районында. Иң кызыгы, күнче һөнәрен белүчеләр безнең якта бик күп булып чыга. Бу ни дигән сүз инде? Бу – безнең татар элек-электән күн итекчитекләрдән йөргән дигән сүз. Әлбәттә, татар чабаталы заманда да яшәп алган, тик кайбер тарихи чыганакларда язылганча, ул чабатаны эш арасында гына кигән, ягъни кунакка-фәлән барганда, үзебезчә әйтсәк, кешелеккә кимәгән. Чабата борынгы Русьта иң таралган, мактаулы аяк киемнәренең берсе булган, диләр. Татар чабата кимәгән, дип һич кенә дә кистереп әйтергә җыенмыйбыз. Кигән, хәтта «татар чабатасы» дигән сүзләр дә яши. Димәк, чабатаны да үзенчә үргән ул. Ә бабаларыбызның күн аяк киемнәреннән йөрүен тарихчылар татарларның күпләп терлек асраулары, димәк, төп чимал – күнгә кытлык булмавы белән дә аңлаталар.

Ярый, буласы булган инде. Ә менә XX гасыр башында артельләрдән башланган һөнәрчелек Казан арты читекләрен берләштергән беренче зур артель төзелүгә китерә. Аңа Габдулла Тукай исеме бирәләр.

1941 елның мартында Тукай артеленнән аерылып, Колачы авылында «Труд» мөстәкыйль артеле оештырыла. Ватан сугышы елларында анда фронт өчен аяк киемнәре тегәләр. Ә инде 1950 нче елдан соң күнчеләр хезмәте яңа төсмерләргә байый башлый: мозаикалы аяк киемнәренә ихтыяҗ арта, ассортимент байый, ир-атлар өчен күн, хром итекләр, хатын-кызлар өчен милли бизәкле читек-чүәкләр, спорт өчен, балалар өчен аяк киемнәре тегәләр. Яңа технологияләр барлыкка килә. 1972 елда Арчада милли аяк киемнәре җитештерү берләшмәсе ачыла. Берләшмәдә 1200 кеше эшли, продукция чит илләргә дә җибәрелә. 1980 елда Лейпциг халыкара ярминкәсендә арчалылар җитештергән күн эшләнмәләр һәм аяк киемнәре Алтын медальгә лаек була.

Тарихка тукталуыбыз юкка түгел. Без гомер буе тарихтан үрнәк-гыйбрәт алып яшәү кирәклеге турында сөйләшәбез. Шул ук вакытта, әледән-әле тарихка кул селтибез дә, еллар узгач, җимерелгәнне, беткәнне яңадан торгыза башлыйбыз. Арчаның милли аяк киемнәре берләшмәсе дә базар шартларына яраклаша алмый. «Чимал җитми, акча кереме кими, товарга ихтыяҗ бетте…» дигән сәбәпләр белән берләшмәне ябып куялар. Беренчедән, базар шартларын бераз үзгәртеп, «кыргый базар шартлары» дип әйтергә кирәктер. Берләшмәне «акционерлык җәмгыяте» итү, ягъни авыр заманда шәхси кулларга бирү үзе үк кыргыйлык саналырга тиеш дип уйлыйм. Илнең, бу очракта Татарстанның йөзен билгели, аны дөньяга таныта торган эшчәнлек дәүләт күзәтүе астында булырга, дәүләт хәер-фатыйхасы белән эшчәнлек җәелдерергә тиеш иде кебек.

Бүген милли мәдәни мирасыбызны, халык һөнәрчелеген үстерү, ягъни үткәнне кайтару турында яңадан зурдан кубып сүз башладык. Кырлай музеенда оештырылган күргәзмәгә халык һөнәрчелеге язмышы өчен җавап бирүче оешма җитәкчеләре чакырылуын сүздән эшкә күчәргә җыенуның галәмәте дип кабул иттем. Шунысын да әйтик: быел Кырлайдагы Тукай музее директоры урынбасары Фердинанд Кавиев Россия Президентының иҗади проектларга ярдәм итү буенча грантына ия булган. Аның «Безнең мирас» күн мозаика эшләнмәләре күргәзмәсе оештыру һәм халык һөнәрчелеген үстерү буенча осталык дәресләре үткәрү» проектына бер миллион сум акча бирелгән икән. Алинә Мөхәммәтшина әйтүенчә, осталык дәресләрен музей бинасында һәм Арча балалар сәнгать мәктәбендә уздырырга ниятлиләр. Менә бу урында күңелгә: «Соңга калмыйбыз микән инде?» – дигән уй да кереп алды. Очрашуга заманында Арча милли аяк киемнәре берләшмәсендә эшләгән Фәридә Кәлимуллина да чакырылган булган. Ул да: «Соңга калмадык микән?!» – дип шикләнә. Чөнки күн мозаикасы белән шөгыльләнүчеләр инде бик аз калган, санарга бер кулның бармаклары да җитә бугай. Яшь буынга үз һөнәрләренең серләрен нәкъ менә алар аңлатырга тиеш. Ә күн мозаикасы эшләнмәләре төрле бизәкләр итеп киселгән күн кисәкләреннән кул белән җыела. Ягъни аларны станокларда күпләп чыгарып булмый. Бәлки, буладыр да, әмма алар табигый матурлыкларын югалтачак. Тора-бара күн мозаикасы сәнгате белән шөгыльләнә торган роботлар да уйлап табарлар, бәлки. Кем әйтмешли, кайчан була әле ул?! Ә күн мозаикасы белән шөгыльләнүчеләрнең һәркайсының үз чигү алымнары, җөй ясау үзенчәлекләре бар икән.

Хәтта тарихка «Казан җөе» дигән төшенчә дә кереп калган.

Энә, без, шөшле тоткан куллар кабатланмас әсәрләр тудыра, дияргә батырчылык итәбез. Кул эше озакка бара, шуңа күрә читек-чүәкләр шактый кыйбат тора. Бүген Арчада үз өендә эшләүче бер оста – Айрат Солтанов белән телефон аша сөйләшеп алган идем. Мәсәлән, хатын-кыз читеге тегү өчен ике ай чамасы вакыт кирәк, ди. Бәясе дә 30–35 мең сум тирәсе булачак. Мондый бәягә милли аяк киеме алучы булырмы? Очрашуда катнашучыларның кайбер фикерләре мондыйрак: беренчедән, чәчәкле-бизәкле читек-чүәкләрне, башка эшләнмәләрне күпләп-күпләп чыгармаска кирәк, фабрика ачып, анда йөзләгән оста җыюның да хаҗәте юктыр. Инде «базар икътисады» дип сөйләнәбез икән, без күн эшләнмәләренә ихтыяҗ нинди икәнен дә өйрәнергә тиеш. Рәсми статистика буенча, Казанга ел саен 3 миллионнан артык турист килә, алар арасында мөселман илләреннән булганнары да шактыйдыр. Алар арасында табигый күннән тегелгән уңайлы аяк киемнәренә, бизәкле мендәрләргә, декоратив панноларга, диван ястыкларына кызыгучылар булмас дисезме? Күн эшләнмәләренең ассортименты байый да бара бит әле. Безгә, артка борылып карый-карый, алга барырга кирәк. Күн мозаикасы кебек уникаль бренд хөкүмәт ярдәменә дә мохтаҗ. Соң чиктә бу югары сәнгать дәрәҗәсенә җиткерелгән һөнәрчелек дөньяга татарны татар итеп таныйтыр иде. Димәк, ул ЮНЕСКО дәрәҗәсендә рәсмиләштерелсә дә әйбәт булыр иде.

Риман ГЫЙЛЕМХАНОВ

Автор фотолары

ХАТ ТАШУЧЫ АСИЯ

Арабыздан беребез

Чистай районының Татар Баганалысы авылына килеп чыккач, Асия апа Миңнебаева белән серләребез бигрәк тә туры килде. Сәбәбе дә бар. Ул шушы авылда гомере буена почтада эшләгән. Миңа да бу һөнәр бик таныш. Мәктәптә укыган елларда, әниебезгә булышып, урам буенча зур почта сумкасы күтәреп йөргән чаклар күп булды.

Элек ничек иде?

Мәктәпне тәмамлагач, Чистай педучилищесына керергә талпынып карый әле Асия апа. Тик үтә алмый. Аның каравы, авылда эш килеп чыга: газета-журналлар тарата башлый. Берничә елдан почта начальнигы да булып куя.

– Безнең заманда эшләргә авыр иде, – дип искә ала ул. – Почтаны зур юлда калдырып китәләр иде. Посылкаларга кадәр шуннан җилкәгә күтәреп ташыдык. Кайчагында, бигрәк тә бәйрәм вакытларында көненә 30–40ар була иде. Авылдан да күп җибәрделәр. Шәһәрдәге туганнарына ит, бәрәңгеләргә кадәр салдылар. Газета-журналларның күплеген әйтеп тә тормыйм инде. Икешәр-өчәр сумка тутырып чыга идек. Бер гаиләгә 3–4 басмадан да ким килмәде бит ул чакта. Халык укып та карады инде. Бәйрәмнәргә җибәрелгән открыткаларның күплеге тагын! Яңа ел, 8 Март көннәрендә шуларны тарату үзенә бер күңелле була торган иде. И-и, халык көтеп ала иде дә инде шул котлауларны. Матур сүзләрне, менә шулай язган бит дип, укып-укып күрсәтәләр иде. Бер ялгансыз әйтәм, ул вакытта почта авылны берләштереп тора иде.

Беләм инде, Асия апаның әле сөйләми калдырган сүзләре дә бихисап. Бигрәк тә ураза вакытларында посылкаларны зур чанага салып, өй борынча төннәр буе тарата идек без. Болай озакка калуның сәбәбе дә бар. Юл хакы дип, әби-бабайлар посылка ачканны көттереп торалар да, чәй эчәрсез дип, кулга кәнфит-печенье тоттырып чыгаралар иде. «Сездә дә шундый хәлләр бар идеме?» – дип сорыйм Асия ападан. Елмаеп кына куя. Булган инде, димәк. Соң, безнең татар әби-бабайларның кунакчыллыгына чикләр бармыни?

Әби-бабайларга хат ташучы бик кирәк иде шул ул вакытларда. Өй тутырып үскән балалар таралышып беткән. Кайсы көньякта, кайсы төньякта дигәндәй, хатлар күп килә. Кем юньләп укый белми, кемнең күзе күрми: укып бирәсең инде, әле ахырында, хатны укып биргән кешегә рәхмәт, дигән сүзләр дә була торган иде.

Шуңа күрә хат ташучының сер сыйдыра, күп сөйләшми торганы, итагатьлесе кирәк иде авылда. Асия апаны да нәкъ менә шундый дип мактадылар. Хөкүмәт тә бәяләгән аның эшен. Күкрәгенә «Коммунистик хезмәт ударнигы» билгесен таккан. Мактау кәгазьләре дә бихисап.

Әмма, әйтергә кирәк, шул ук вакытта теләсә кайсы хат ташучы күңелсез хәлләрне дә исенә төшерә ала. Татар Баганалысында да бервакыт шулай семинар кебек чара уза. Шул көнне төнлә белән почтаны басалар. Югалган әйберләрнең суммасы уртача өч айлык хезмәт хакына тигез була. Өч ай бушлай эшли Асия апа. «Яртысын гына алып калыгыз инде, зинһар», – дип ялынып, районга бара. Әмма риза булмыйлар, ишетмәмешкә салышалар. Туксанынчы елларда поездларда посылкалар ачу «мода»га кереп киткән иде. Ул хәлләрне дә искә төшердек. Хат ташучыларга бер гаепсезгә күпме авылдашларының каргышын тыңларга туры килде бит ул вакытларда. Асия апа үзе беркемне дә гаепләми, үпкә тотмый. «Еладым-еладым да беркая да бармадым. Кулыннан тотмаган каракны карак дип әйтеп булмый инде, үз авылың бит», – дип кенә куйды.

Шушы авылда туып-үскән Асия апа, механизатор булып эшләүче Фәрит исемле егет белән тормыш корган, биш бала үстергәннәр. 2004 елда лаеклы ялга чыккан. Аңа карап кына эштән туктамаган. Дөрес, урам буйлап хат өләшеп йөрми инде. Әмма мәдәният йортында иң актив ветераннарның берсе. «Кызлар чакырса, хәзер килеп җитәм, җырлыйбыз да, биибез дә, чигәбез дә, бәйлибез дә», – ди үзе дә. Уңышлары да юк түгел: «Җәлил укулары» бәйгесендә районда икенче урынны алып кайткан. Авылда бер генә бәйрәм дә аннан башка үтми. Гаиләсендә дә бик кирәкле кеше әле Асия апа. Кызы Ясминәнең ире баласы туганчы ук вафат булган. Шуңа күрә оныгы Солтан күбрәк әбисе янында. Тагын бер кызы Ләйсән дә ерак китмәгән, Чистайда эшли. Гел аралашып, ярдәмләшеп торалар.

Хәзер ничек?

Сүзебез һаман шул почта эшчәнлеге турында инде.

– Хәзер үзенә бер авыр, – дип башлады сүзен Асия апа, – газета-журналларга яздырып булмый. Күбесе программа өчен генә языла. Телевизор карауны өстенрәк күрәләр. «Газета яздырып укыгыз. Бик әйбәт нәрсәләр бар бит», – дип әйткәләгәнем бар. «Яңалыкларны карарга телефон бар бит хәзер. Газетаны барыбер бик соңарып китерәләр», – диләр. Монысы да дөрес. Әмма эш анда гына да түгел. Авыл бик картайды. Беренче чиратта яшьләрне авылда калдыру чарасын эзләргә иде. Моның өчен эш урыннары булдыру кирәк. Хәзер күбесе Чистайга йөреп эшли үзе. Ул да бик ышанычлы түгел бит. Авылда яшьләр калса, тормыш рәтләнеп китәр, газета укучылар да табылыр кебек.

Ничек кенә булмасын, авыл кешеләренең мул тормышта яшәгәненә сөенә Асия апа. Эш юк дип кайгырып ятмыйлар: күп итеп терлек-туар асрыйлар. Кибет тотучы, терлек, кош-корт асраучы эшмәкәрләре дә бар. Инвесторлар, җир мәйданына карап, игенен дә китерә, Өлкәннәр көненә бүләген дә биргән икән.

Бүләк дигәннән, почта системасына бу җәһәттән үпкә белдереп алды Асия апа. «Ничә еллар эшләп, искә алучы да юк. Бик күңелсез булды, – ди. – Нишлисең инде, почта бик үзгәрде бит хәзер. Бар белгәннәре – товар саттыру, акча эшләтү. Акча турында гына уйланган җирдә халык мәнфәгатьләрен кайгырту юктыр инде ул. Товарны пенсия белән китереп бирәләр. Бер яктан яхшы да инде ул. Үземә кирәклеләрен мин дә алып калам. Яхшы түгел бит. Хат ташучылар үзебезнеке. Аларга да план бирәләр. Планны үтәсәң генә премия аласың. Халык арасында риза булмаганнары да очрый, әлбәттә. Яраксыз товар калдыргансың дип, кире илтеп бирүчеләр дә бар. Шулай итеп, хат ташучыларның кайгысы да, баш бәласе дә товар сату булып калды. Мин йөрим инде, хәзер элмә тактаны «почта-кибет» дип язарга кирәк дип. Шаяртып кына әйткән булам, әмма дөресе шул бит». Ни кызганыч, Асия апаның сүзләре белән килешмичә булмый шул.

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА



Наил ШӘРИФУЛЛИН

Давылларда, җилләрдә...

Магнит давылы дигән күренешне җентекләп белмәсәк тә, аның кеше организмына кире йогынты ясаганын чамалыйбыз кебек. Һава торышын фаразлаганда метеорологлар да, бер-ике сүз белән булса да, геомагнит хәл хакында белдереп тора. «Кояш җиле» дигән төшенчәне дә ишеткәнебез бар. Тик асылын бик белеп бетермибез. Гомумән дә, тотып карап, күреп булмаган, тик тәэсире сизелгән, аерым очракларда ул тәэсир зарарлы, хәтта куркыныч булган хикмәтләр тирә-ягыбызда җитәрлек безнең.

Әле күптән түгел генә республикабыз районнарында төннәрен безнең киңлекләр өчен гадәти булмаган күренеш – «Төньяк балкышы» күзәтелде. Андый балкышның яралуын галимнәр Җирнең магнит кырының Кояштан килгән «җил» – корылган кисәкчекләр ташкыны белән бәрелеше аркасында туа дип аңлата. Магнитлы сфера дип аталган калкан безне гадәттә Кояштагы көйсезлекләрдән булдыра алганча саклый. Бары полюсларга якын тарафларда гына, магнит кыры юка булу сәбәпле, кисәкчекләр ионлы сферага үтә. Ягъни балкыш дигәнебез чынлыкта поляр әйләнәнең теге ягында гына күзәтелергә тиеш. Ләкин...

Ләкин балкыш безнең тарафларга ук килеп җиткән икән, димәк, Кояшта моңарчы күзәтелмәгән активлык ералган, ул тарафтан килгән «җил» көчле өермә рәвешен алган дигән сүз. Нәкъ шушы хәл гадәттән тыш көчле магнит давылы – Җирнең магнит кырының кискен тынычсызлануын, «җил» белән бил алышып, хәлсезләнүен китереп чыгарырга сәләтле, һәм чыгара да. Башкача әйткәндә, Кояш ипле булганда, Җирнең магнит кыры да ипле, тыныч; Кояш дулаган чакларда исә магнитлы сферада да буран котыра – аномалияләр барлыкка килә. Безнең сәламәтлек тә нәкъ шул чакларда сынала.

Магнит давылларының үз расписаниесе дә бар, диләр. Алар якынча 27 көнгә бер ярала дигән нәтиҗә яши. Кайчакта «график» үзгәреп тә куя икән. Һәрхәлдә, белгечләр төгәл фаразны бары бер яисә ике көнгә генә алдан биреп булуны ассызыклый. Кояшта вак шартлаулар, протуберанецлар ералуын күргән, аларның вакытын белгән метеорологлар, ничә сәгатьтән соң ионлашкан ташкынның безнең планетага җитәсен, аның көчен хәзер шактый төгәл билгели. Шуңа күрә кайбер мәгълүмат чараларының, аерым «белгеч»ләрнең атналык, айлык фаразларына ышану, аларга карап профилактика чаралары куллану, дарулар кабул итү һич тә дөрес түгел, диясе килә. Аларга ышану хәтта куркыныч та. Шушы җәһәттән галимнәр тәҗрибә дә үткәргән. Ике төркем туплап, беренчесен «Иртәгә көчле магнит давылы булачак»ка ышандырганнар, икенче төркемгә: «Геомагнит кыры тыныч кала», – дип дөресен әйткәннәр. Нәрсә килеп чыккан дисезме? Беренче төркемдәге хәтсез кеше, ихтимал, русча «самовнушение» дип аталган нәрсә нәтиҗәсендә начар кәефтән, хәтта хәлсезлектән зарлана башлаган. Кемнәрдер даруга ук үрелгән. Биредә, ирексездән, бер акыллы башның: «Сакланып, котылып булмастай куркыныч хакында бөтенләй белмәвең хәерлерәк», – дигән сүзе искә төшә.

Тик, әйткәнебезчә, магнит давылы хакында безне ким дигәндә бер көн алдан кисәтеп торалар. Бу юллар авторы давыл көтелгән көнне кан басымын көйли, иртән урталай бүлеп эчә торган даруны тулы килеш йотып куя. Шулай итмәсәң, басым гадәттә бер ун-унбиш берәмлеккә югарырак күтәрелергә дә мөмкин. Давылның кешенең психикасына, йөрәк-кан юллары системасы торышына кире тәэсире күптән исбатланган. Германиядә, мәсәлән, юл-транспорт фаҗигаләренең 50 процентка якыны елның геомагнит вазгыять нык кискенләшкән 4–5 көненә туры килүен даими билгелиләр. Теләсә кайсы табиб, инфаркт, инсульт кебек авыр хасталарның, хроник чирләр көчәюенең күбесенчә шундый көннәргә туры килүен искәртә ала, искәртә дә. Галимнәр исә бу хәлләрне кеше затының аерым күзәнәкләрдән торуы, һәр күзәнәкнең үз ритмы булуы, магнит давылының шул ритмны бозуы белән аңлата.

Кеше – кеше инде, «тимер»дән ясалган электроника булып, ул да без әйткән давылга шактый сизгер. Армиядә чакта берсендә өч сәгатьтән артыкка «Молния-2» тибындагы ике ясалма иярченне тәмам югалткан, дөресрәге, алар белән элемтәсез калган хәтердә. Мондый гадәттән тыш хәл аркасында кайберәүләр катыдан-каты шелтә, иң югарыда «разбор полетов» көтеп йөргәндә, эшнең әлеге дә баягы шул магнит кырының чыгымчылавы, бигрәк тә алда искәрткән протуберанецлар җибәргән «җил»нең шуклыгы аркасында булуы ачыкланды. Җирдәге техниканы магнитлы сфера барыбер күпмедер дәрәҗәдә саклый әле. Ә галәмдәге электрониканы корылган кисәкчекләр аяусыз утка тотканда катлаулырак хәлләр күпкә ешрак килеп чыгарга да мөмкин. Бүген Җир тирәли төрле илләр менгергән йөзәрләгән ясалма иярчен әйләнеп йөрүен искә алганда, ел саен аларның дистәгә якынының алда искәртелгән сәбәп аркасында эштән чыгуына гаҗәпләнәсе дә юктыр...

Без күрмәгән, тотып карый алмаган, тик безгә йогынтылы көчләр... Кеше затының танып белү мөмкинлекләре фән-техника, технологияләр үсеш алган хәзерге заманда да бик чамалы, чикле. Адәми зат үзе яшәгән тирәлекне, галәм дип аталган макродөньяны, аңа капма-каршы булган микромасштабны (мәсәлән шул ук вируслар цивилизациясен) күбрәк өйрәнгән саен үзенең бик тә аз белгәненә төшенә. Безнең бит җәмгысы биш төрле тоемлау ысулыбыз бар: күрәбез, ишетәбез, ис сизәбез, кул белән тотып карый алабыз, тәм рецепторларыннан файдаланабыз. Шуның белән шул. Электромагнит дулкыннар, радиация генә түгел, кайбер тереклек ияләре ишеткән ультра һәм инфратавыш та безнең өчен юк. Чынлыкта булып та. Аның ишене приборлар ярдәмендә сизәргә, билгеләргә өйрәнсәк тә, без барлыгын белмәгән бихисап күренешләр әле ачылмаган. Кешелек исән булып, тагын берничә йөз ел үтүгә, белгәннәребез бермә-бер артыр, тирәлегебезне яхшырак аңлый, төшенә, аннан килгән йогынтыларга нәтиҗәлерәк каршы тора башларбыз, дип ышанасы килә.

Авырткан җирдән кул китми

Туган тел буенча БДИ тапшыручылар саны аз булу, якшәмбе мәктәпләренә белгечләр җитмәү, яңа дәреслекләр. Татарстан Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитетының чираттагы утырышында әнә шулар хакында фикер алыштылар. Бу юлы очрашу Татарстан Халыклар дуслыгы йортында узды.

Россия Мәгърифәт министрлыгы федераль дәреслекләрнең яңа исемлеген әзерли. Республика анда татар теленнән яңа укыту-методик комплекслар кертелүен көтә. Бу хакта күчмә утырышта Татарстан мәгариф һәм фән министры Илсур Һадиуллин әйтте.

– Исемлек ел саен яңартыла. Бу – Татарстан өчен җитди вакыйга, чөнки без анда татар теле һәм башка фәннәр буенча тәрҗемә ителгән яңа дәреслекләрне кертергә телибез, – дип сөйләде министр.

Илсур Һадиуллин әйтүенчә, исемлеккә башка фәннәр буенча тәрҗемә ителгән дәреслекләрне кертү катлаулы. Алар Россия халыклары телләрендә нәшер ителгән дәреслек буларак тәкъдим ителә.

Тагын бер борчыган мәсьәлә. Республика мәктәпләрендә туган телне өйрәнүче укучыларның нибары тугыз проценты гына бу фәннән төп дәүләт имтиханын сайлый икән. Быел республикада андый укучылар саны 2 меңнән артык булган.

– Без бу күрсәткечләрдән бөтенләй канәгать түгел, чөнки бу бик аз. Әлеге юнәлештә эшне дәвам иттерергә кирәк, – диде Илсур Һадиуллин. – Бер атнадан республика районнары белән сөйләшүләр башлана. Анда туган телләрне сайлауга бәйле мәсьәләләрне күтәрәчәкбез.

9 нчы сыйныфта имтихан тапшыру өчен үз туган телен 44 районнан 2502 укучы сайлаган. Уртача билге – 4,4 балл.

– Барлык телләр буенча да уңай динамика күзәтелә, әмма без тагын да яхшырак булдыра алабыз, – дип өстәде министр.

Утырышта якшәмбе мәктәпләре эше турында да фикер алыштылар. Төрле милләтләрнең гореф-гадәтләрен, сәнгатен, мәдәниятен балаларга җиткерү максатыннан оештырылган мәктәпләр бу. Нигездә, алар үз эшчәнлеген Халыклар дуслыгы йортлары базасында алып бара. Мәгариф һәм фән министры сүзләренә караганда, республиканың 110 якшәмбе мәктәбендә 25 милләтнең теле өйрәнелә. Чуаш телен өйрәнү буенча бүлекләр иң күбе – 19. Аларга 302 бала йөри. 16 бүлектә мари телен, 13 бүлектә удмурт телен өйрәнәләр. Татарстанда якшәмбе мәктәпләре булмаган районнар да бар. Алар арасында – Әлки, Әтнә, Балтач, Югары Ослан, Кайбыч, Лаеш һәм башкалар. Андый районнар барлыгы 14.

Бу юнәлештәге төп проблемалар турында Казанның Вахитов районы күпмилләтле якшәмбе мәктәбе директоры Маринэ Хухунашвили сөйләде. Аның сүзләренә караганда, иң авырткан җир – белгечләр җитмәү.

– Профессиональ стандартлар кертелгәч, без кадрлар сайлауда кыенлыклар белән очраштык. Элек без тел белгән кешене укытырга ала алсак, хәзер аларның педагогик белеме булу таләп ителә. Әлеге проблеманы хәл итү өчен, «Өстәмә белем бирү педагогы» белгечлеге буенча әзерләүгә финанслар эзлибез, – дип сөйләде директор.

Ләйсән САФИНА

Авыл җаны

УКЫТУЧЫ ДА БӘРӘҢГЕ АШЫЙ

Илдар Мөхәммәтҗанов

Укытучы турында язу җиңел дә, кыен да. Аның җәмгыятьтәге ролен әле күккә кадәр күтәрәләр (бигрәк тә Укытучылар көнендә), әле бөтен бәлаләрнең башы аларда дип, түбән төшереп бетерәләр.

Илдәге сәяси системаның торышына да ул гына гаепле, чөнки сайлаулардагы закон бозуларга күз йома. Әйтерсең башкалар бөтен уйлаганнарын кычкырып әйтәләр. Мәгариф системасының таралып ятуына, балаларның белемсезлегенә дә ул гына гаепле. Әйтерсең башка өлкәләр чәчәк ата!.. Бу рухта озак дәвам итеп булыр иде. Хакимият безнең җәмгыятьнең көзгесе булган кебек, укытучы да үзе яшәгән җәмгыятьтән әллә ни аерылмый инде ул.

Мин, әллә ни тирәнгә кереп тормыйча, авыл укытучылары портретына берничә штрих кына сызып үтәргә телим. Бу инде «Укытучы да бәрәңге ашыймыни?» – дип аптыраган чор түгел, барыбыз да беләбез.

Бүгенге әңгәмәдәшем – химия һәм биология укытучысы. (Язманың каралама вариантын укыгач, исемен күрсәтмәүне сорады, гәрчә мин булдыра алган кадәр «йомшартыбрак» язган кебек идем. Авылда калуының сәбәбе авыру әтисен, аннары ул вафат булгач, әнисен ялгыз калдырмаска теләве. Аннары кияүгә чыга, ике бала таба. «Шәһәргә китсәң, иртәрәк китәргә кирәк булгандыр», – ди хәзер.

Югары категорияле укытучы ул; димәк, үзеннән-үзе аңлашылганча, көненең абсолют күп вакыты мәктәптә, мәктәп, дип, укучылар, дип үтә. Димәк, тырыш, җаваплы, максатчан. Дүрт бердәм дәүләт имтиханына әзерлисе бар. Гадәттә, бер консультация түләүле, калганнары түләүсез. Ләкин «югары категорияле» дигән статус андый «вак-төяк» белән исәпләшеп торырга кушмый. Үземнән беләм. Иң мөһиме – нәтиҗә. Укучыларының имтихан нәтиҗәләре яхшы: сиксәннең өсте дә, җитмешнең өсте (баллар турында сүз). Утыз алты сәгать. «Нигә шулкадәр күп?» – дигәнгә, укытучылар җитеп бетми икән. Яшьләр ул хезмәт хакына килергә атлыгып тормый.

Сыйныф җитәкчесе дә. Эшләр русча алып барыла, чөнки татар сыйныфлары юк. Кайчандыр татар сыйныфлары ачылуына шатлана-шатлана, барлык фәннәрне дә татарча укытып йөргән вакытлар тарихка кереп бара икән инде.

Хезмәт стажы – егерме җиде ел. «Эшли башлагандагы белән чагыштырганда, төп аермалар нидә?» – дип сорыйм. «Хәзер мәгълүмат күп, үзеңә кирәкле бар мәгълүматны табарга була, видео, аудиоматериаллар күп, ләкин эшләү элек кызыграк иде, ди ул. Без элеккеге совет чоры методикалары белән эшли башладык, алар белемне ныграк истә калдырырга ярдәм итә иде», – ди.

Хәзер тагын бер күзгә ташланган аерма бар икән. Туксанынчы еллар балаларының балалары укый хәзер һәм ул ата-аналар белән эшләү шактый кыен икән. Кайчандыр, мәсәлән, Ә.нең үзен эзләп табып алып килә идек мәктәпкә, хәзер аның балалары – шул ук юлда, ди. Алма агачыннан ерак төшми инде. Җитмәсә, әле бертуктамый укытучылар өстеннән язып та тора андыйлар: «Ата-ана һәрвакыт хаклы».

Мин мәктәптән киткәндә, Федераль дәүләт стандартлары дигән нәрсә керә башлады мәгариф системасына. Аның төп асылы укучының фикерләү дәрәҗәсен үстерү булса да, утыз алты сәгать укыткан укытучының ул стандартлар буенча дәрес планнарын язуын күз алдына китерү шактый кыен. Үзем бөтен пунктына туры китереп бер тапкыр гына шундый планны язып карадым. Ике сәгать ярым вакытымны алды ул дәрескә әзерлек. Әле тагын биш дәрес көтеп тора иде... Зарланмасмы, дигән идем дә, электән проблемалы укыту тарафдары булганга, ФГОСтан зарланмый мөгаллим. «Эшеңне үзең тиеш дип санаганча эшлисең, тикшерүчеләр өчен – интернет тулы дәрес эшкәртмәләре, чыгарып аласың да, үзеңә җайлаштырасың. Телисеңме-юкмы, яраклашырга өйрәтә система».

«Синең өчен тормышта иң мөһиме нәрсә?» – дим. «Балаларның бәхете, уңышы, сәламәтлек, – дип җавап бирә ул. – Иң сөендергәне – эштәге уңышлар, үзеңне кирәкле итеп тою», – ди.

Ниләр борчый? «Бәлки, тормыш юлымда җибәргән хаталардыр. Тәвәккәллек аз булудыр...»

Тәвәккәллегә җитсә, бик күп укытучының эшен алыштырырга теләвен беләм мин. Үзеңчә эшли алмасаң, теләгәнеңне әйтә алмасаң, фотоотчет, видеоотчетлар аша һәрчак күзәтчелек астында булсаң, иң яратып башкарган хезмәтең дә ялкыта, эмоциональ яктан яндыра, мәгънәсез тоеладыр ул. Мин шулай уйлыйм.

Лилия ФӘТТАХОВА

ҺИЧ ОНЫТАСЫМ ЮК

Гаиләбез истәлекләре

Сырпы тапмадым

Әти-әниебезнең беренче уллары 3–4 яшьләрендә бер-бер артлы дөньядан китәләр... «Киләчәктә өебезнең тәрәзәләре саен балаларыбыз булсын иде, дип еладык әтиең белән икебез», – дип сөйли иде әнием... Теләкләре тормышка аша. «Фәрештәнең «Амин!» дигән сәгатенә туры килгәндер», – диләр безнең якларда мондый очракларда. Алар алты бала тәрбияләп үстерәләр. 1938 елда олы апабыз Флера, 1941 елда Марсель абыебыз туа. 1942 елның мартында әтием сугышка киткәндә, әнием ике бала белән кала.

Тылдагы халык совет солдатларына кирәк-яраклар җибәреп тора. Авылдашлардан фронтка җибәрү өчен җылы оекбашлар, бияләйләр җыю укытучыларга тапшырыла. Башлангыч мәктәп директоры буларак, бу эшкә әнием җаваплы була. Күп вакыт, ишекләрне тыштан бикләп, балаларның үзләрен генә өйдә калдырырга туры килә аңа. Берсендә шулай соң гына өйгә кайтып керсә, ни күрсен! Идәнгә он сибелгән, идән уртасында онга «баткан» апаем Флера басып тора... Кулларына камыр ябышкан, алҗып беткән. Болай да зур матур кара күзләре тагы да зурайган сыман, аптырап карап торалар... «Ипи пересәсе (пешерәсе) идем, сырпы (шырпы) тапмадым, әнием», – ди 4 яше дә тулмаган апаем... Бар булган онны су белән болгатып бетергән... Ничек әле «сырпы» тапмаган!!! Каһәр суккан сугыш тудырган авырлыкларга тешен кысып түзеп, сер бирмичә яшәгән әнием, апаемны кочып, үксеп елап җибәрә... Ярый әле фаҗига булмый кала!!! Ярый әле әнием шырпыларны «ерак» яшерә торган була!

Курчаклар да беткәндер инде

Бөек Ватан сугышына безнең авылдан – Арча районы Урта Бирәзә авылыннан бик күп ир-егетләр китә. Шулар арасында урамыбызның каршы ягындагы күршебез Гарәпша абый да. Аның кызы Мәрһәмбикә белән минем апаем Флера бик дус булалар. Менә бер вакыт сугыштан Гарәпша абый яраланып кайта. Кызына бүләккә курчак алып кайта. Дус кызының курчагы белән минем апаем да уйный, бик кызыга курчакка. Җитмәсә, әтием дә сугышка киткәндә апаема: «Әниеңне тыңла, тәти, акыллы бул кызым, яме! Мин сиңа курчак алып кайтырмын», – дип әйткән була... Шуны исенә төшергәндер инде апаем. Бер көнне шулай, Мәрһәмбикәнең курчагы белән уйнаганнан соң өйгә кайткач: «Әтием кайтмый да кайтмый, курчаклар да беткәндер инде...» – дип сөйләнеп утыра...

Фәрдия СӘФӘРГАЛИЕВА

Хөрмәтле укучыларыбыз!

Өлкәннәргә дә, яшьләргә дә мөрәҗәгать итүебез: нәкъ менә балачактагы хатирәләрне күңелегездә яңартып, «Һич онытасым юк» сәхифәсенә язмалар юллагыз әле. Үзегезгә үткәнгә кайтып килү булса, башкаларга соклану, йә булмаса гыйбрәт алу булыр.

Сихри көз

Җир төренгән алтын төскә,
Юлдагы сулар туңган.
Урам чатында усал җил
Тарткалый мине кулдан.

Карлы яңгыр йөзгә бәрә,
Сафлык өреп күңелгә.
Елмаеп мыек астыннан
Кояш тора көләргә.

Йөзеп арган болытлар да
Туктап йокыга талган.
Җил, тырышып, болытлардан
Ак буразналар салган.

Көн җылытып эретсә дә,
Елгалар ташып акмый.
Бала-чага уйнаса да,
Аларга кызу капмый.

Яңа яуган кар шыгырдый,
Шундый рәхәт күңелгә.
Онытылып шул җәннәттә,
Их, чабып бер йөрергә!

Римир СӘЛИМГӘРӘЕВ

Илдар Мөхәммәтҗанов

ЛЕГИОНЧЫ ГОМӘР

Район газетасында эшләгәндә, иртәнге якта Сарманнан эзтабар язучы Дамир абый Гарифуллин килеп керде. Китаплары, җырлары аша бик тә танылган, абруйлы кеше.

– Әсгать, Октябрь Бүләге авылыннан Асибаков фамилияле кешене белмисеңме? – дип сүз башлады ул.

– Беләм, беләм, Дамир абый, районыбызда бик тә данлыклы, эшсөяр кешеләр, тулы бер династия алар! – дидем.

– Муса Җәлилнең тугры, данлы көрәштәше, Франциядәге антифашистик подполье җитәкчесе, беренче макизары, 1944 елның июнендә французлар белән бергә Югары Луара департаментын азат итүче, үз Ватанына әйләнеп кайткан 4000нән артык совет хәрби әсирен коллыктан коткаручы, сугыштан соң Казанда яшәүче Әмир Үтәшев белән күрешкәч тә, ул фотолары белән таныштыра башлады, – дип дәвам итте сүзен Дамир абый. – Менә француз хатын-кызлары, ир-атлары белән бергә төшкән рәсем. Әмир ага чүгәләбрәк утырган берәүгә төртеп күрсәтте дә: «Бу безнең пропагандистыбыз һәм китапханәчебез иде», – диде. Һәм мин шул мизгелдә рәсемгә карадым да телсез калдым, маңгаемнан салкын тир бәреп чыкты – фотодагы кеше минем абыем Гокәшә иде. Әмир ага сөйләвен дәвам итте: «Муса Җәлилнең Габбас Шәрипов, Нигъмәт Терегулов аша безнең партизан отрядына килеп кергән шигырьләр дәфтәре аның кулында күп булды: ул дәфтәрне күчерә-күчерә милләттәш егетләргә бүләк итте».

– Менә бу сырлап эшләнгән урындыкка утырган берәү янында да минем абыем басып тора, – дидем мин, тагын гаҗәпләнеп.

– Әйе, ә ул утыргычта утырганы – Азнакай районы егете Гомәр Асибаков, Октябрь Бүләге авылыннан.

Дамир абый, шулай итеп, бу исемне иң беренче нәкъ менә Әмир ага Үтәшевтан ишетүен әйтте. Гомәр белән Франциянең Югары Луара департаментында партизан отрядында танышканнар һәм үзе аларның командиры булган. Исемнәре французча язылган француз партизаннары исемлегендә дә торган.

Без Асибаковларга барырга кузгалдык. Әлбәттә инде, мин юлда шул нәселдәге атказанган исемнәре алган,

Гокәшә Хәйруллин (уңда) һәм Гомәр Асибаков – Франциянең каршылык күрсәтү хәрәкәтендә актив катнашкан макизарлар. Рәсем Франциянең Югары Луара департаментындагы Ле-Пюн шәһәрендә 1945 елның 25 февралендә төшерелгән.

хөкүмәт бүләкләренә лаек кешеләр турында сөйләп бардым. Менә Октябрь Бүләгенә дә килеп ирештек. Бәхеткә Гомәр абый өйдә иде. Дамир абый хәл-әхвәлләрен сорашып, акрын гына Гомәр абыйның телен ачарга тырышты. Гел-гел куркуда, күзәтүдә яшәгән, әсир исеме алган ветеран, бераз үксебрәк куйды да, ачылып китте. Шул тиклем киеренкелектә торган-яшәгән ул, әле берничә ел элек кенә сугышта катнашучылар исемлегенә кертелеп, II дәрәҗә Дан ордены бирелгән. Бөек Октябрь революциясе яшьтәше. 1940 елда хәрби хезмәтен тутырып кайтуына, бер ел да үтми, 1941 елның июлендә сугышка китә. Ләкин Полтава юнәлешендәге сугышларда фашистлар боҗрасында калып, әсирлеккә төшәләр. Тора-бара, күп мәхшәрләр аша, Польшага килеп эләгә һәм татар легиончысы булып китә. Тик «Идел-Урал» легионы вермахтның ышанычын акламый, Көнчыгыш фронтка җибәрелгән легиончылар һәрдаим Совет Армиясе йә совет партизаннары ягына күчәләр. Нәтиҗәдә нацистлар татар легионын Франциягә күчерәләр. Гомәр Асибаков та Франциянең Югары Луара департаментына килеп эләгә һәм Франциянең каршылык күрсәтү хәрәкәтендә катнашучы булып китә. Арада иң күбен татарлар алып торган лагерьдан партизаннарга качуын Әмир Үтәшев оештыра. Партизаннар отрядлары командующие Серж Запальский: «Татар егетләре – кыю һәм куркусыз партизаннар», – дип әйтә торган була. Гомәр Асибаковның монда генерал де Голль бүләге – Франция ордены белән бүләкләнүе дә шуны күрсәтә.

Әсирлек, сугыш аның сәламәтлеген нык какшата. 1945 елның декабрендә Грозный шәһәренә кайтып, нефть промыселларында эшли башлагач, озак та тормый инвалидлыкка чыга һәм Октябрь Бүләгенә кайта. Тик анда да тынгылык юк: әсирлектә булганга гел сорау алулар, тикшерүгә чакырулар булып тора, беркем белән дә элемтәдә тормаска киңәш итәләр. Бар юаныч гаиләсендә: терлек асрап, бакчачылык белән көн күрә. Өч кызы, өч улы үскәндә дә күп кыенлык, кимсетүләр кичерә.

– Нишлисең, үземне гаепле санадым. Сталин законнары буенча сугышта әсир төшү җинаять иде бит, – диде Гомәр ага. – Ә минем соңгы минутта үзем өчен дә патроным калмаган иде, әллә ничә кешегә бер мылтык...

Һәм, гомумән, Гомәр абый кебек ачы язмышлы кеше белән сөйләшү гомердә бик сирәк туры киләдер.

Мәгълүм ки, соңыннан Әмир Үтәшевның партизаннар отрядыннан 352 нче совет батальоны оеша, алар регуляр Совет Армиясе сугышчылары булып китәләр. Әлбәттә инде, тоткынлыкта Муса Җәлилләр ниятләгән гаять катлаулы бурычны ахырына кадәр үтәп чыгуда катнашкан Гомәр Шәехвәли улы Асибаковны – гомере буе тәмуг кичкән легиончы партизанны онытырга тиеш түгелбез. Үз чиратыбызда, Сарманда яшәүче тынгысыз эзтабар әдибебез Дамир абыйга чиксез рәхмәтлебез! Гомәр абый белән очрашып-сөйләшүне һич онытасыбыз юк.

Әсгать СӘГЫТДИНОВ.
Азнакай районы

БЕР ЯЛГАН СҮЗ

Кара көннәр

Бибисара Буа районы Карлы авылында крестьян гаиләсендә туа. Әтисе – 1887 елгы Һидиятулла Галиулла улы – җир эшкәртеп, терлек асрап көн күрә, үз куллары белән крестьян хуҗалыгында эшкә кирәкле әйберләр дә ясый. Агачтан кар көрәү, иген чистарту, бәрәңге казу өчен көрәк, сәнәк, балта, чүкеч саплары, тырма, арба тәртәләре һәм шуның ише башка нәрсәләр. Кыр эшләре тәмамлангач, күршесе Зариф белән сәүдә эшләрен дә алып баралар. Берничә елдан гаилә тагын 4 балага арта. Балалар кече яшьтән тормыш йөген тартырга өйрәнәләр. 3 ир бала – әтиләренә, 2 кыз әниләренә ярдәмләшеп үсәләр. Габитовлар гаиләсе авылда эшчән, тырыш, бар яктан үзләрен тәэмин итеп яшәүче, урта хәлле булып санала.

Чуаш ягындагы урманнардан алып кайткан таза бүрәнәләрдән төзелгән 5 стеналы йорт, мунча, терлекләр тотар өчен уңайлы абзар, ике ат, сыер, сарык-

лар, каз, тавык барысы да үз көчләре белән булдырылган. Калай башлы йорт ерактан ук хуҗалыкта ипле куллар булуын күрсәтә.

Шулай тырышып-тырмашып яшәп ятканда, 1930 елның урак өстендә, гаилә кырдагы эштән кайтып кергәндә, өйләренең таланып беткәненә тап була. Бәйдәге эт хуҗаларын елап каршы ала. Аннары үз гаебен таныгандай шыңшып елап, оясына кереп ята. Һидиятулла вакыйганы авыл советына барып хәбәр итә. Әмма аннан ярдәм булмый. Авылда ың-шың таралып, урлаучылар ачыклана башлагач, шул ук шәхесләр Буа НКВДсына Габитовларның кулак булуы турында хәбәр җиткерә. Һәм бу хәлләргә 1930 елның 29 октябрендә көтелмәгәнчә нокта куела. Габитов Һидиятулла, аның 68 яшьлек әтисе Габитов Галиулла кулга алыналар. Ике ай да үтми, 1931 елның 22 гыйнварында Җинаять кодексының 58-8, 58-10 маддәләре буенча хөкем ителеп, Һидиятулла – 10 елга, 68 яшьлек әтисе Галиулла 5 елга лагерьга озатылалар. (ҖК 58-8, 58-10 маддәләре террор акты әзерләүдә гаепләнүне аңлата.) Тырышып хезмәт итеп, дәүләткә саллы налог түләүче, 5 бала тәрбияләүчеләр икесе дә, кызганычка, Сталин лагерьларында билгесез шартларда юкка чыгалар. Ә гаиләләренә «халык дошманы» тамгасы сугыла. Суд карары авылга билгеле булуга, йорт сүтеп алына. Тагын берничә кешенең өен сүтеп, авыл янәшәсендә мәктәп оештырыла. Чәчү җирләре, ат, сыер, сарык, сука, сабан, тырма һәм башка эш коралларын яңа оешып килүче колхоз активистлары үзләштерәләр. Әниләре Бибигайшә белән биш балага кара мунчада яшәргә кала. 1932 елның кышкы салкыннарында 5 яшьлек Рифкать салкын тидереп үлеп китә. Әтиләреннән һәм бабаларыннан лагерьдан бер хәбәр килми. Шул ук вакытта, авылдан гаиләләрне ерак җирләргә сөрә торалар. Карлы авылында сөргенгә хөкем ителүчеләр 34 кешегә җитә. Бибисара, яз җиткәч, шулай ук советлардан таланып калган гаилә егете Гыйматдинов Низамга кияүгә чыгып, Мәскәүгә китә.

Расих ҖӘЛӘЛ.
Буа районы Карлы авылы

P.S. Язманың дәвамы киләсе «Һич онытасым юк» сәхифәсендә.

КАЙГЫ УРТАКЛАШУ

КОЗАРЬ НИКОЛАЙ ФЕДОРОВИЧ
(26.02.1942 – 19.11.2023)

Татарстан Республикасы җәмәгатьчелеге авыр югалтуга дучар булды.

Элекке Татарстан Республикасы Президенты Эшләр идарәчесе Козарь Николай Федорович 19 ноябрь көнне 82 нче яшендә арабыздан мәңгегә китте.

Николай Козарь 1942 елның 26 февралендә Алтай крае Славгород шәһәрендә дөньяга килгән. 1964 елда В.И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университетын тәмамлаган.

Совет Армиясе сафларында хезмәт иткәннән соң, В.И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университетының гомуми физика кафедрасы ассистенты сыйфатында хезмәт эшчәнлеген дәвам иттергән, комсомол эше белән шөгыльләнгән. 1969–1973 елларда ВЛКСМның Казан университеты комитеты секретаре, ВЛКСМның Казан шәһәре Совет районы комитеты икенче секретаре һәм Вахитов районы комитетының беренче секретаре вазыйфаларын биләгән.

1973 елда ТАССР Министрлар Советы Эшләр идарәсенең сәнәгать һәм транспорт бүлеге җитәкчесе итеп билгеләнгән. 1977 елда КПСС Үзәк комитеты каршындагы Югары партия мәктәбен тәмамлаганнан соң, ТАССР Министрлар Советы Тәэминат идарәсе җитәкчесенең беренче урынбасары булган.

Николай Федорович 1984–1986 елларда Татарстан АССР Матди-техник тәэминат буенча дәүләт комитеты рәисе вазыйфасында эшләде. 1986 елда ТАССР Министрлар Советының Эшләр идарәсе җитәкчесе булды. 1991 елда Татарстан Республикасы Президентының Эшләр идарәчесе вазыйфасына билгеләнде.

Николай Козарь Татарстан Республикасында дәүләтчелекне торгызуга үзеннән зур өлеш кертте. Аның һөнәри осталыгы һәм югары квалификациясе нәтиҗәсендә Татарстан Республикасы Президенты эшчәнлеген тәэмин итүнең нәтиҗәле системасын булдыруга ирешелде. Гражданнарның хокукларын һәм ирекләрен, законлылык һәм хокук тәртибен, иҗтимагый иминлекне тәэмин итү буенча республиканың югары вазыйфаи заты эшен оештыру өчен кирәкле барлык шартлар тудырылды. Ул һәрвакыт административ, финанс, хуҗалык мәсьәләләрен лаеклы төстә, нәтиҗәле хәл итте. Үз кул астындагылар өчен үрнәк һәм остаз булды. Шулай ук республика һәм җирле хакимият органнарының өстенлекле бурычларын тормышка ашырырга ярдәм итте.

Николай Козарь, лаеклы ялга чыкканнан соң, иҗтимагый эшчәнлек белән шөгыльләнде, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының Иҗтимагый советы рәисе, Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы һәм Татарстан Республикасы Рәисе администрациясенең Ветераннар советы әгъзасы булды.

Николай Козарь катлаулы һәм киң колачлы бурычларны хәл кылуда югары дәрәҗәдә җаваплылык хисе, эшенә тугрылыгы, профессионализмы, куелган максатка ирешүдәге ныклыгы белән аерылып торды. Эшлекле сыйфатлары һәм кешелеклелеге, ватанпәрвәрлеге, кешеләргә карата игътибарлы мөгамәләсе аңа коллегалары арасында һәм җәмәгатьчелектә зур абруй-хөрмәт китерде.

Николай Козарьның күп еллык нәтиҗәле хезмәте һәм казанышлары югары дәрәҗәдәге бүләкләр белән билгеләнде. Алар арасында – «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены медале, «Фидакарь хезмәт өчен» һәм «Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы оештырылуга 100 ел» медальләре, «Татарстан Республикасының атказанган икътисадчысы» дигән мактаулы исем, Татарстан Республикасы Мактау грамотасы, Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәт хаты.

Козарь Николай Федоровичның якты истәлеге күңелләребездә мәңгегә сакланыр.

Р.Н. МИҢНЕХАНОВ, М.Ш. ШӘЙМИЕВ,
Ф.Х. МӨХӘММӘТШИН, А.В. ПЕСОШИН,
Ә.Ә. СӘФӘРОВ, М.М. СИТДЫЙКОВ,
А.В. ХОХОРИН, И.Р. МЕТШИН,
М.Д. ШӘРИФУЛЛИН, Е.Б. БОГАЧЕВ,
З.Р. ВӘЛИЕВА, Х.Г. ИШТИРӘКОВ,
И.В. ТЕРЕНТЬЕВА

Татарстан Республикасы Рәисе администрациясе, элекке Татарстан Республикасы Президентының Эшләр идарәчесе

КОЗАРЬ Николай Федорович

вафат булу сәбәпле, мәрхүмнең гаиләсе һәм якыннарының авыр кайгысын уртаклаша.
Николай Федорович Козарь үз эшенең остасы, талантлы һәм җаваплы җитәкче, мәрхәмәтле остаз иде. Аның якты истәлеге күңелләребездә мәңгегә сакланыр.

Республика агросәнәгате ветераннар советы,

Рәсим Мокатдәс улы ЗИННӘТУЛЛИН

вафат булу сәбәпле, гаиләсенең, туганнарының авыр кайгысын уртаклаша. Рәсим Мокатдәсовичка 85 яшь иде. Ул – республика авыл хуҗалыгын үстерүгә үзеннән зур өлеш керткән шәхес, заманында Баулы, Минзәлә районнарында хезмәт куйды, Биектауда авыл хуҗалыгы идарәсе җитәкчесе булды, «Сельхозэнерго» тармагындагы эшчәнлеге дә югары бәяләнде, бик күпләр аның үрнәгендә тәрбияләнде. Урыны оҗмах түрләрендә булсын!

«Татарстан» дәүләт телерадиокомпаниясе коллективы һәм ветераннар советы, хезмәттәшебез, Татарстанның халык артисты Тәлгать Гали улы Хаматшинның бертуган апасы

Фәния Гали кызы ХАМАТШИНАның

вафат булуы сәбәпле, якыннарының һәм туганнарының тирән кайгысын уртаклаша.

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОННАРЫ

«Татарстан Республикасында гражданнарның җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар уздыру хокукларын гамәлгә ашыру шартларын тәэмин итү турында» Татарстан Республикасы Законының 10 статьясына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан
2023 елның 2 ноябрендә кабул ителде

1 статья

«Татарстан Республикасында гражданнарның җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар уздыру хокукларын гамәлгә ашыру шартларын тәэмин итү турында» 2012 елның 25 декабрендәге 91-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 10 статьясындагы 8 өлешенең 5 пунктына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2012, № 12 (II өлеш); 2014, № 7; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 33 (I өлеш); 2020, № 4 (I өлеш); 2021, № 20 (I өлеш); 2023, № 20 (I өлеш), аны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«5) «ВЕ» һәм «СЕ» категорияләре өчен 15 берәмлектән (барлыгы).».

2 статья

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль, 2023 ел, 16 ноябрь, № 107-ТРЗ

«Татарстан Республикасында хайваннарга карата мөнәсәбәт өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 4 статьясына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан
2023 елның 2 ноябрендә кабул ителде

1 статья

«Татарстан Республикасында хайваннарга карата мөнәсәбәт өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2019 елның 27 декабрендәге 120-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 4 статьясындагы 1 өлешенә (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2020, № 4 (I өлеш), № 26 (I өлеш); 2021, № 93 (I өлеш); 2022, № 77 (I өлеш), аңа түбәндәге эчтәлекле 5^1 пункт өстәп, үзгәреш кертергә:

«5^1) хуҗасыз хайваннарга карата мөнәсәбәт буенча эшчәнлекне гамәлгә ашырганда чаралар оештыру;».

2 статья

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль, 2023 ел, 16 ноябрь, № 108-ТРЗ

«Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 4 һәм 5 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан
2023 елның 2 ноябрендә кабул ителде

1 статья

«Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2012 елның 22 декабрендәге 87-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2012, № 12 (I өлеш); 2013, № 12 (I өлеш); 2014, № 6 (II өлеш), № 7; 2015, № 3, № 10 (I өлеш); 2016, № 3, № 7 – 8; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 25 (I өлеш); 2017, № 52 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 54 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2019, № 28 (I өлеш); 2020, № 26 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2021, № 29 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 34 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2023, № 3 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 48 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4 статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 13^4 пункт өстәргә:

«13^4) ел саен Татарстан Республикасы Дәүләт Советына Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеге торышы турында доклад тәкъдим итү;»;

2) 5 статьяга түбәндәге эчтәлекле 16^6 пункт өстәргә:

«16^6) Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеге торышы турында еллык доклад әзерләүне һәм аны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге үзенең рәсми сайтында урнаштыруны гамәлгә ашыру;».

2 статья

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль, 2023 ел, 16 ноябрь, № 109-ТРЗ

«Татарстан Республикасында янгыннан ирекле саклау турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан
2023 елның 2 ноябрендә кабул ителде

1 статья

«Татарстан Республикасында янгыннан ирекле саклау турында» 2011 елның 1 августындагы 48-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2011, № 8 (I өлеш); 2014, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 55 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1 статья. **Әлеге Законны куллану өлкәсе**

Әлеге Законның гамәлдә булуы физик затларга һәм юридик затларга – иҗтимагый берләшмәләргә алар тарафыннан Татарстан Республикасы территориясендә янгыннарны профилактикалауга һәм (яисә) сүндерүгә һәм һәлакәттән коткару эшләрен башкаруга бәйле янгыннан ирекле саклау эшчәнлегендә катнашу хокукын гамәлгә ашыруга бәйле рәвештә кагыла.»;

2) 4 статьяда:

а) исемдә «иҗтимагый берләшмәләр» сүзләрен «янгыннан ирекле саклау иҗтимагый берләшмәләре» сүзләренә алмаштырырга;

б) «янгыннан ирекле саклау буенча иҗтимагый берләшмәләрнең» сүзләрен «янгыннан ирекле саклау иҗтимагый берләшмәләренең (алга таба – янгыннан саклау иҗтимагый берләшмәләре)» сүзләренә алмаштырырга;

3) 5 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5 статья. **Янгыннан саклау иҗтимагый берләшмәләре мөлкәте**

Янгыннан саклау иҗтимагый берләшмәләре мөлкәте Россия Федерациясе законнары нигезендә башлангыч кертемнәр һәм әгъза буларак түләнә торган кертемнәр, әгәр аларны түләү тиешле янгыннан саклау иҗтимагый берләшмәсе уставында каралган булса, аны гамәлгә куючыларның кертемнәре, ихтыяри кертемнәр һәм иганәләр, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары тарафыннан Россия Федерациясе законнары, Татарстан Республикасы законнары, муниципаль хокукый актлар нигезендә янгыннан саклау иҗтимагый берләшмәләренә күрсәтелә торган ярдәм чаралары исәбеннән әлеге уставка таянып үткәрелә торган чаралардан кертемнәр һәм Россия Федерациясе законнары белән тыелмаган башка кертемнәр (шул исәптән, янгыннан мөлкәтне һәм (яисә) граждан җаваплылыгын иминләштерүне гамәлгә ашыручы иминият оешмалары акчалары) нигезендә туплана.»;

4) 7 статьяны үз көчен югалткан дип танырга;

5) 8 статьяда «Янгыннан ирекле саклау командалары (дружиналары)» сүзләрен «Ирекле янгын сүндерү бүлекчәләре» сүзләренә алмаштырырга;

6) 9 статьяның 1 пунктында «янгыннан саклау буенча иҗтимагый берләшмәләр хезмәткәрләрен һәм анда катнашырга теләүчеләрне» сүзләрен «янгыннан саклау иҗтимагый берләшмәләренең ирекле янгын сүндерүчеләрен һәм янгыннан ирекле саклау хезмәткәрләрен» сүзләренә алмаштырырга.

2 статья

Әлеге Закон 2024 елның 1 февраленнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль, 2023 ел, 16 ноябрь, № 110-ТРЗ

«Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарына граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан
2023 елның 2 ноябрендә кабул ителде

1 статья

«Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарына граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен бирү турында» 2005 елның 30 декабрендәге 146-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 12 (IV өлеш); 2007, № 1 (I өлеш), № 11; 2008, № 10 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш); 2011, № 5; 2013, № 10; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 33 (I өлеш); 2018, № 44 (I өлеш); 2019, № 40 (I өлеш), № 79 (I өлеш); 2020, № 57 (I өлеш); 2022, № 90 (I өлеш); 2023, № 27 (I өлеш), 1 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«Татарстан Республикасында җирле
үзидарә органнарына граждан хәле
актларын дәүләт теркәвенә алу
вәкаләтләрен бирү турында»
Татарстан Республикасы Законына
1 нче кушымта

Муниципаль районнарның административ үзәкләре булмаган, җирле үзидарә органнарына тууны, никахлашуны, аерылышуны, атасын билгеләүне, вафат булуны дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләре бирелә торган шәһәр һәм авыл җирлекләре исемлеге

№ т/б	Шәһәр һәм авыл җирлекләре исеме	Муниципаль район исеме
1	Актүбә шәһәр тибындагы поселогы	Азнакай муниципаль районы
2	Түбән Мактама шәһәр тибындагы поселогы	Әлмәт муниципаль районы
3	Урман-Кәләй авыл җирлеге	
4	Рус Акташы авыл җирлеге	
5	Яңа Кенәр авыл җирлеге	Арча муниципаль районы
6	Сеҗе авыл җирлеге	
7	Иске Кырлай авыл җирлеге	
8	Ташкичү авыл җирлеге	
9	Үрнәк авыл җирлеге	
10	Шушмабаш авыл җирлеге	
11	Карабаш шәһәр тибындагы поселогы	Бөгелмә муниципаль районы
12	Березовка авыл җирлеге	
13	Иннополис шәһәре	Югары Ослан муниципаль районы
14	Васильево шәһәр тибындагы поселогы	Зеленодольск муниципаль районы
15	Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы	
16	Әйшә авыл җирлеге	
17	Норлат авыл җирлеге	
18	Осиново авыл җирлеге	
19	Кама Аланы шәһәр тибындагы поселогы	Түбән Кама муниципаль районы
20	Каенлы авыл җирлеге	
21	Шәмәрдән авыл җирлеге	Саба муниципаль районы
22	Җәлил шәһәр тибындагы поселогы	Сарман муниципаль районы

».

2 статья

Әлеге Закон 2024 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль, 2023 ел, 16 ноябрь, № 111-ТРЗ

Татарстан Республикасы Экология кодексына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан
2023 елның 2 ноябрендә кабул ителде

1 статья

Татарстан Республикасы Экология кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 1; 2010, № 5 (I өлеш); 2011, № 6 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2012, № 1; 2013, № 1; 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 7; 2015, № 4; 2016, № 1 – 2, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 40 (I өлеш), № 44 (I өлеш); 2017, № 27 (I өлеш); 2018, № 54 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 19 (I өлеш); 2020, № 4 (I өлеш), № 37 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш); 2021, № 20 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 34 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2023, № 27 (I өлеш), № 35 (I өлеш); № 48 (I өлеш); № 56 (I өлеш), № 81 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) преамбулада «хуҗалык» сүзен «икътисадый (хуҗалык)» сүзләренә алмаштырырга;

2) 8 статьяда:

а) 1 өлештә:

түбәндәге эчтәлекле яңа утыз тугызынчы һәм кырыгынчы абзацлар өстәргә:

«каты коммуналь калдыклар белән эш итү хезмәтләрен күрсәтү шартнамәләре буенча исәп-хисаплар ясау максатларында каты коммуналь калдыкларның күләмен һәм (яисә) авырлыгын исәпләү ысулын билгеләү, каты коммуналь калдыклар белән эш итү хезмәтләрен күрсәтү шартнамәләре буенча исәп-хисаплар ясау максатларында региональ оператор һәм (яисә) каты коммуналь калдыклар белән эш итү хезмәтен кулланучы тарафыннан каты коммуналь калдыкларның күләмен һәм (яисә) авырлыгын исәпләү ысулын сайлау тәртибен раслау;

әйләнә-тирә мохиткә тупланган зыян объектларын ачыклау;»;

түбәндәге эчтәлекле кырык беренче абзац өстәргә:

«әйләнә-тирә мохиткә тупланган зыянны бетерүне оештыру;»;

утыз тугызынчы абзацны кырык икенче абзац дип санарга һәм анда «әйләнә-тирә мохиткә тупланган зыян объектларын ачыклау һәм бәяләү, һәм (яисә) әйләнә-тирә мохиткә тупланган зыянны бетерү эшләрен оештыру» сүзләрен «әйләнә-тирә мохиткә тупланган зыян объектларын ачыклау һәм (яисә) әйләнә-тирә мохиткә тупланган зыянны бетерүне оештыру» сүзләренә алмаштырырга;

кырыгынчы абзацны кырык өченче абзац дип санарга;

б) 2 өлештә «кырыгынчы» сүзен «кырык өченче» сүзләренә алмаштырырга;

3) 96 статьяның 1 өлешендә «башка эшләр» сүзләреннән соң «су турындагы законнар,» сүзләрен өстәргә.

2 статья

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль, 2023 ел, 16 ноябрь, № 112-ТРЗ

«Гражданнарның гаражларга һәм алар урнашкан җир кишәрлекләренә хокуклар алуына бәйле аерым мәсьәләләрне җайга салу турында һәм Татарстан Республикасы Җир кодексының 3 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законының 2 һәм 3 статьяларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан
2023 елның 2 ноябрендә кабул ителде

1 статья

«Гражданнарның гаражларга һәм алар урнашкан җир кишәрлекләренә хокуклар алуына бәйле аерым мәсьәләләрне җайга салу турында һәм Татарстан Республикасы Җир кодексының 3 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2021 елның 3 ноябрендәге 85-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2021, № 93 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 статьяның 3 өлешендә «Җирле үзидарә органнары» сүзләрен «Муниципаль районнарның, шәһәр округларының җирле үзидарә органнары» сүзләренә алмаштырырга;

2) 3 статьяның 1 өлешендә:

а) беренче абзацта «Гаражлардан» сүзен «Җирле үзидарә органнары тарафыннан гамәлгә ашырыла торган һәм гаражлардан» сүзләренә алмаштырырга;

б) 1 пунктта «җирле үзидарә органнары» сүзләрен «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары» сүзләренә алмаштырырга;

в) 2 пунктта «җирле үзидарә органнарына» сүзләрен «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына» сүзләренә алмаштырырга.

2 статья

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль, 2023 ел, 16 ноябрь, № 113-ТРЗ

Татарстан Республикасы Җир кодексының 32 һәм 32^1 статьяларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан
2023 елның 2 ноябрендә кабул ителде

1 статья

Татарстан Республикасы Җир кодексына (2005 елның 18 гыйнварындагы 4-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1998, № 8 (II өлеш); 2005, № 1 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2006, № 7 (I өлеш); 2007, № 1 (I өлеш), № 4; 2008, № 5 (I өлеш); 2009, № 7 – 8 (III өлеш); 2010, № 11; 2011, № 11 (I өлеш); 2012, № 3, № 5 (I өлеш); 2013, № 1; 2014, № 3, № 5, № 6 (II өлеш), № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2016, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 40 (I өлеш); 2017, № 41 (I өлеш), № 52 (I өлеш), № 76 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 22 (I өлеш), № 78 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 60 (I өлеш); 2020, № 77 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 20 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 3 (I өлеш), № 17 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2023, № 11 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 56 (I өлеш), № 73 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 32 статьяның 3 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Өч һәм аннан күбрәк баласы булган гражданнарның җир кишәрлеге бирү турында гариза бирү көненә кадәр биш ел дәвамында Татарстан Республикасы территориясендә даими яшәве турында әлеге пунктның 1 пунктчасында каралган таләп, ата-ананың берсе генә булса да яисә ялгыз ата йә ана хәрби хезмәткәр булса, кулланылмый.»;

2) 32^1 статьяның 10 пунктында:

а) түбәндәге эчтәлекле 10 пунктча өстәргә:

«10) «Хәрби хезмәткәрләр статусы турында» 1998 елның 27 маендагы 76-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә хәрби хезмәткәр статусын таныклаучы документ (ата-ананың берсе яисә ялгыз ата йә ана хәрби хезмәткәр булса).»;

б) түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Әлеге пунктның 9 пунктчасында күрсәтелгән документ гариза бирүче «Хәрби хезмәткәрләр статусы турында» 1998 елның 27 маендагы 76-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә хәрби хезмәткәр статусына ия булган очракта тапшырылмый.».

2 статья

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль, 2023 ел, 16 ноябрь, № 114-ТРЗ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЛАРЫ

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының кырык тугызынчы утырышын чакыру турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **КАРАР БИРӘ**:

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының кырык тугызынчы утырышын 2023 елның 23 ноябрендә 10 сәгатьтә Татарстан Республикасы Дәүләт Советының утырышлар залында чакырырга.

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе
вазыйфаларын башкаручы Ю.З. Камалтынов

Казан шәһәре, 2023 елның 17 ноябре, № 2227-VI ДС

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының кырык тугызынчы утырышы каравына кертелә торган мәсьәләләр турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **КАРАР БИРӘ**:

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының кырык тугызынчы утырышы каравына түбәндәге мәсьәләләрне кертергә:

1. «2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 485-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (II укылыш).
2. «2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты турында» 486-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (II укылыш).
3. «Татарстан Республикасы Бюджет кодексы аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору турында һәм 2024 елда Татарстан Республикасы бюджет системасы бюджетларын үтәү үзенчәлекләрен билгеләү хакында» 503-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
4. «Татарстан Республикасында автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыруның аерым мәсьәләләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 501-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
5. «Татарстан Республикасында урманнардан файдалану турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 500-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
6. «Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 502-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
7. «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 505-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
8. «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 8^1 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 504-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
9. «Татарстан Республикасында гражданнарның мөрәҗәгатьләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 488-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (II укылыш).
10. «Татарстан Республикасында гражданнарга патриотик тәрбия бирү турында» 479-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (II укылыш).
11. «Эскроу счетлардан файдаланып төзелеш подряды шартнамәләре буенча торак йортлар төзү турында» 471420-8 номерлы федераль закон проекты хакында (шәхси йортлар төзүдә һөнәри подрядчы оешмаларны проекттагы финанслау турында).
12. «Россия Федерациясенең аерым закон актларына «Эскроу счетлардан файдаланып төзелеш подряды шартнамәләре буенча торак йортлар төзү турында» Федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә үзгәрешләр кертү хакында» 471417-8 номерлы федераль закон проекты турында (шәхси йортлар төзүдә подрядчы оешмаларны проекттагы финанслауны кертүгә бәйле рәвештә законнарны камилләштерү хакында).
13. «Россия Федерациясе Салым кодексының икенче өлешендәге 149 статьясына үзгәреш кертү турында» 471415-8 номерлы федераль закон проекты хакында (подрядчы эшләрен өстәмә бәягә салым салудан азат итү турында).
14. «Пестицидлар һәм агрохимикатлар белән куркынычсыз эш итү турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 471418-8 номерлы федераль закон проекты турында.
15. Хөкүмәт сәгате: «Россия Федерациясе Пенсия иминияте һәм социаль иминият фондының Татарстан Республикасы буенча бүлеге эшчәнлеге турында».

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе
вазыйфаларын башкаручы Ю.З. Камалтынов

Казан шәһәре, 2023 елның 17 ноябре, № 2228-VI ДС

Дәүләт Советы депутатлары игътибарына

Алтынчы чакырылыш Татарстан Дәүләт Советының кырык тугызынчы утырышы 23 ноябрь көнне (10.00 сәгатьтә башлана) Дәүләт Советы утырышлар залында үткәрелә.
Депутатлар Дәүләт Советы бинасында 23 ноябрьдә 8.00 сәгатьтән башлап теркәлә.
Белешмәләр алу өчен телефон: 267-63-62.

КОТЛЫЙБЫЗ!

«Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы каршындагы Татарстан юл-транспорт комплексын карап тоту һәм үстерү баш идарәсе» дәүләт казна учреждениесенең оештыру эше бүлеге башлыгы **Акимов** Айрат Рәшит улына, «Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы каршындагы Татарстан юл-транспорт комплексын карап тоту һәм үстерү баш идарәсе» дәүләт казна учреждениесе директорының төзелеш буенча урынбасары **Хөсәенов** Ринат Фидаил улына, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының гражданлык хәле актларын теркәү бүлеге баш белгече **Әхмәтова** Альбина Рафаэль кызына, Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының режим, мобилизация әзерлеге, граждан оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр бүлеге башлыгы **Белоусов** Алексей Борисовичка, «Татарстан Республикасының Баш инвестиция-төзелеш идарәсе» дәүләт казна учреждениесенең реставрация бүлеге баш белгече **Герфанова** Ольга Валентиновнага, «Татарстан Республикасының Баш инвестиция-төзелеш идарәсе» дәүләт казна учреждениесенең үзәк территориаль бүлеге башлыгы урынбасары **Хафизова** Алия Наил кызына, «Татарстан Республикасының Баш инвестиция-төзелеш идарәсе» дәүләт казна учреждениесенең Кама аръягы территориаль бүлеге баш белгече **Шәрифуллин** Равил Әгъдәс улына, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының калдыклар белән эш итү бүлеге башлыгы **Краснова** Диана Викторовнага, «Вафауллин Ансель Альберт улы» крестьян (фермер) хуҗалыгы башлыгы **Вафауллин** Ансель Альберт улына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Агросәнәгать комплексы, җир мөнәсәбәтләре һәм кулланучылар базары идарәсе агросәнәгать комплексы, җир мөнәсәбәтләре һәм җирдән файдалану секторы мөдире **Исламов** Руслан Рустам улына, «ТӨНЬЯК» АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ ПРЕДПРИЯТИЕСЕ» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте баш икътисадчысы **Котдусов** Фаил Фәрадис улына, «Ташкын» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры **Сәлихянов** Рәүхәт Сәлихян улына, «Нигез» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры **Җәлилов** Дамир Әмин улына, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы Махсус техник чаралар бюросының 6 бүлеге 6 бүлекчәсе башлыгы **Горшков** Павел Александровичка, Татарстан Республикасы прокуратура органнары ветераны **Шәйфетдинов** Җофар Габдрахман улына, Әлмәт муниципаль районының ветераннар (пенсионерлар) җирле иҗтимагый оешмасы рәисе урынбасары **Минһаҗева** Клара Бисәнгали кызына, Әлмәт муниципаль районының ветераннар (пенсионерлар) җирле иҗтимагый оешмасы президиумы әгъзасы, Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Татарстан Республикасы Әлмәт районы буенча бүлеге ветераннары башлангыч ветераннар оешмасы рәисе **Ярмиев** Рәшит Исхак улына, «ВодоТехноСервис» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте баш бухгалтеры урынбасары **Әгълиуллина** Рәйдә Рәсим кызына, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы» муниципаль казна учреждениесе рәисе урынбасары **Әхмәтҗанова** Лилия Рашат кызына, «Татарстан Республикасы техник инвентаризация һәм кадастр эшләре бюросы» акционер җәмгыятенең финанс бүлеге баш бухгалтеры урынбасары **Костина** Алина Львовнага, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Контроль-хисап палатасы рәисе **Насыйбуллина** Гөлнара Насыйх кызына **Татарстан Республикасы Рәисенең Рәхмәте** белдерелде.

***

Татарстан Республикасы мәнфәгатьләрендә күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен хезмәт ветераны **Евграфова** Анна Ильковна **«Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены медале** белән бүләкләнде.

***

Рухи-әхлакый хәзинәләрне саклауга һәм үстерүгә зур өлеш кертүләре һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре өчен «Рус Православие Чиркәвенең Казан епархиясе Казан православие дини семинариясе» дини оешмасы – дини югары белем бирү мәгариф оешмасы хезмәткәрләре: китапханә мөдире **Асяева** Наталия Анатольевна, физик тәрбия җитәкчесе **Круглов** Евгений Анатольевич, филология һәм гомуми гуманитар дисциплиналар кафедрасы доценты **Петрова** Маргарита Михайловна, филология һәм гомуми гуманитар дисциплиналар кафедрасы профессоры **Чернышева** Алефтина Юрьевна **Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале** белән бүләкләнде.

***

Конфессияләр арасында татулыкны һәм тынычлыкны ныгытуга зур өлеш кертүләре өчен «Рус Православие Чиркәвенең Казан епархиясе Казан православие дини семинариясе» дини оешмасы – дини югары белем бирү мәгариф оешмасы хезмәткәрләре: протоиерей, гомуми тарих һәм чиркәү тарихы кафедрасы мөдире **Колчерин** Алексей Сергеевич, административ-хуҗалык часте буенча проректоры **Наконечный** Алексей Александрович, протоиерей, литургия-канон дисциплиналары кафедрасы өлкән укытучысы **Павлов** Александр Петрович, протоиерей, ректор **Самойленко** Владимир Михайлович **«Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел» медале** белән бүләкләнде.

Язучы сүзе

Марат КӘБИРОВ

Гомер

Гомергә бер ышанган нәрсәсе түгел иде, әллә нишләп күрәзәчегә барасы итте. Үзе генә булса, бармас иде инде. Иптәш егетенең сүзе сәбәпче булды бугай:

– Әйдә, кереп чыгабыз. Унбиш минут вакыт узар инде. Файдасы тисә тияр, тимәсә нәрсә... Бер зыяны да юк.

Күрәзәче карчыкның капка төбенә килеп туктагач та кире борылырга мөмкин иде әле. Кермәскә уйлаган да иде инде. Тик ниндидер зәхмәт ирек бирмәде. Үз аягы белән керде ул. Кеше тырмага да үз аягы белән баса. Ирексездән үз аягы белән керде. Күрәзәче карчыкның көче тәэсир итте бугай. Бер карасаң, керүе яхшыга да булды.

Бу киноларда күрсәтелгәнчә, әллә нинди очлы башлыклар киеп, муеннарына беләкләренә тимер-томыр тагып, шәм яндырып, төтен чыгарып утыра торган кортка түгел иде. Гади генә әби. Урамда күрсәң, күрәзәче икән дип тә уйламассың. Дусның өенә кереп, аның әбисе белән хәл-әхвәл белешеп утырган кебек кенә булды барысы да. Һәм шуның бер мизгелендә әби әйтеп куйды:

– Үзең турында берни дә әйтмим. Шөкер итеп кенә торырлык. Синең бик яраткан этең бар. Менә ул бик нык авырый.

Егетнең күзе маңгаена менде, чөнки, чынлап та, эте бар һәм ул соңгы арада бераз хәлсезләнебрәк тора иде. Тик бу карчык аны каян белгән?! Хәер, шуңа да күрәзәче бит инде ул.

– Аны берәр ничек дәвалап буламы соң?

– Була, – диде әби кемнеңдер сүзен тәрҗемә иткәндәй, – тик ул тиздән үләчәк.

Күрәзәче бүтән сүз әйтмәде.

Кайтуына эте чынлап та оясында хәлсезләнеп ята иде. Егет, аны күтәреп алып, район үзәгенә җилдерде, анда хайваннарны дәвалый торган урын бар иде. Фәлән сумын чыгарып салып, иң абруйлы дигән врач янына керде. Тикшерделәр. Анализларын алдылар, әллә нәрсәләр кыландырдылар. Кыскасы, сүтеп кенә җыймадылар этне. Ләкин анык кына итеп: «Этегез шундый-шундый чир белән интегә», – диярлек диагноз куя алмадылар.

Катгый диагноз куя алмасалар да, бер кочак дару, бер дәфтәр киңәш язып бирделәр. Даруларның берсен дә калдырмый төяп алып кайтты. Этнең хәлен яхшырта торган ризыклар да алырга куштылар. Кешечә әйтсәң, эт диетасы була инде. Аларны да алды. Боларны күргәч, иптәш егете әйтеп куйды:

– Кара әле, синең этеңне дәвалау ат бәясенә төшә түгелме соң?

– Төшсен!

Эте, чынлап та, аңа кадерле иде. Эшеннән ял сорап алып, бер атна буе этен карады. Режим белән ашатты, дарулар бирде, прогулкада йөртте, массаж ясады. Аны аякка бастыру өчен нәрсә эшләргә мөмкин – барысын да эшләде. Этнең карашына җан керде. Менә бу караш... Ул мәхәббәтнең үзе шикелле иде. Бу күзләр аңа карамады, ә нур булып, җылылык, яктылык, ягымлылык һәм ярату булып җанына ягылды. Шушы карашны күрү өчен генә дә әллә ниләр эшләргә мөмкин иде.

Бер атна дигәндә, эте терелде. Эт үзе дә сөенә, хуҗасын да сөендерергә тели: берчә аңа килеп сырпалана, берчә ары йөгереп китә дә күккә сикереп, гимнастлар сыман әйләнеп чыга, берчә цирк осталары сыман койма башыннан йөгерә, тагын әллә нәрсәләр кылана. Һәм егет бу тамашаның үзенә багышлануын аңлый, этенең рәхмәте дип кабул итә һәм бар булмышы елмаюга күмелә иде.

Шундый уеннарның берсендә эт койма аша сикереп чыкты да... җилдереп капка төбенә килеп туктаган иптәш малаеның машинасы астына эләгеп җан бирде.

Һәм егет үкенде. «Әгәр этем оясында авырып яткан булса, ул болай уйнакламас һәм машина астына эләкмәс иде», – дип өзгәләнде. Бу уй тынгы бирмәгәч, кабат теге күрәзәчегә китте.

– Ник әйттең син?! – диде ул җан ачысы белән, – әгәр дәваламаган булсам, этем әле исән булыр иде.

– Оясында ятса да, барыбер үләр иде, – диде күрәзәче. – Тик интегеп үләр иде. Ә ул дөньяда үзен яраткан, аның өчен барысын да эшләргә әзер дусты барлыгын аңлап, бәхетле булып китте.

vk.com

ТАТЛЫ АРЧА

Арчаның тәмле тортлары, баллы сый-нигъмәтләре белән бөтен республика халкы сыйлана. Районда татлы бизнес белән кызыксынып, тәмле ризыклар пешерүче осталар аз түгел. Күпчелегенең эшчәнлеге безе тортларыннан башланган. Эшмәкәрләрнең тагын бер уртак ягы – барысы да яшь булу.

Чишмә башы

Арча районында күпләп тортлар пешерүнең чишмә башы – Рәзинә Гарифуллинада, дисәк, ялгыш булмас. 2013 елда бертуган энесе Рәмзилнең тәкъдиме менә шундый зур эшкә башлангыч булыр дип, бәлки, уйламагандыр да ул.

– Әниебез без кечкенә чагында ук «Графские развалины» тортын пешерә иде. Кем килсә дә, гел шул ризыкны әзерләдек. Әнидән күреп, үзем дә пешерә башладым. Бервакыт энем: «Апа, әйдә, сатуга пешереп карыйк әле», – дип тәкъдим итте. Ул вакытта мин икенче балам белән декрет ялында идем. Башта якыннарыбыз бу эшебезнең уңышлы булуына бик ышанып та бетмәде, шуңа күрә теләктәшлек тә күрмәдек. Ләкин барыбер тәвәккәлләргә булдык, – дип искә алды Рәзинә.

Ул вакытта Рәмзил, вакытны озакка сузмыйча, торт пешерер өчен янкорма эшләп куя, мичләр сатып алалар. Балаларының үҗәтлеген күреп, әти-әниләре дә ярдәм кулы суза. Шулай итеп, 5 литрлы миксердан башланган эш 20 литрга кадәр җитә, эшли торган цех та зурая, ярдәмчеләр дә барлыкка килә.

– Тортларны башта энем белән икебез генә пешердек. Ул елны Яңа ел бәйрәменә 30 тортка заказ кабул иттек. Бик күп тоелды ул безгә. Зур көч куелды, тик кулга акча кергәч, күңел дә үсте. Эшне тагын да җәелдерергә булдык, – ди Рәзинә.

Акрынлап аларның татлы сыйлары Арча һәм Казан кибет киштәләренә менеп кунаклый. Безе һәм «Кырмыска оясы» тортлары, пироглар, печеньелар пешерәләр, соңгы вакытта йомырка сарысына гына баскан токмач сата башлаганнар.

– Биш ел бик нык эшләдек. Заказлар искиткеч күп иде. Шуннан соң әлеге эшкә күпләр алынды. «Графские развалины» тортын да күпләр пешерә башлады. Шулай да клиентларыбызның: «Сезнең тортлар иң тәмлесе», – дигән сүзләре йөрәккә сары май булып ята. Без хәзер сан түгел, сыйфат булсын дип эшлибез. Арзанлы чимал кулланмыйбыз, шунлыктан тәмлүшкәләребез бераз кыйммәтрәк бәядән сатыла. Намус белән эшләгәннең әҗере дә бар: ризыкларыбыз һәрвакыт мактаулы, – ди эшмәкәр ханым.

Арчада күпләп тортлар пешерүне Рәзинә Гарифуллина башлап җибәргән.

Гаилә бизнесы

Арчаның тагын бер булдыклы гаиләсе – Камилә һәм Газиз Салиховлар. 2017 елдан башлап әти-әнисе, энесе ярдәме белән тәмле тортлар пешереп, Арча халкын сыйлаучы Камиләнең эшчәнлеге бераздан гаилә бизнесе буларак тамыр җәя.

– Ул вакытта кияүдә түгел идем әле, Газиз белән күрешеп-очрашып кына йөргән чагыбыз. Мин пешергән тортларны ул абыйсы белән бергә кибетләргә куеп сата башлады. Бар эшне бергәләп эшлибез, безнең тортларга да бик күп ярату һәм көч керә, – диде Камилә.

Әнә шулай, бар эшне бердәм һәм бергәләп эшләгәнгә, хезмәтләре уңышлы булып чыга. Аларның тортлары бөтен республика һәм күрше Башкортстан кибетләренә тарала.

Салиховларның да татлы бизнесы безедән башлана.

– Безе тортын әни пешерергә өйрәтте. Башта «сарафан радиосы» аша танылып, кешеләргә заказга әзерләдек. Аннан соң кибетләргә тәкъдим иттек. Бераздан үзләре үк соратып ала башлады. Хәзер инде тәкъдим итеп йөрергә дә кирәкми, илтеп кенә бирәбез. Үз кибетебезне ачу турында да хыялланабыз. Әлегә анысына вакыт җиткереп бетереп булмый, – ди Камилә.

Бүген алар зур цехларында безедән, уалучан камырдан, бисквиттан, катлы камырдан тортлар, чәкчәкләр пешерә.

– Көндәшлек безне куркытмый. Һәркем үз эшен яхшы һәм яратып эшләсә, һәркайсыбызның да сатып алучысы булачак, – дигән фикерне җиткерде Газиз. – Бизнеста иң төп күрсәткеч – сыйфат. Халыкны алдап булмый. Бер тапкыр ишетеп килсәләр, икенчесендә сыйфат артыннан киләләр.

Адаманов

Бу бизнес та безе тортыннан башлана. Рамилә Адаманова башта аларны өендә пешереп сата. Бераздан әлеге эшчәнлекне уллары Ильяс тагын да җитдирәк, төплерәк итеп җәелдерергә алына. Брендларын үзгәртә, эшчеләрне арттыра, ассортиментны киңәйтә, җитештерү цехын зурайтып, башка урынга күчерә, кафе ача, реклама ясый. Ә өйдәге цехта хәзерге вакытта да әниләре чәкчәк пешерә.

– Соңгы вакытта аларны аеруча яратып алалар, чөнки безнең чәкчәкләр бары тик табигый ингредиентлардан гына пешерелә. Бал белән эшләгәнгә күрә, саклану вакыты да озак. Туйлар, мәҗлесләр өчен бик яхшы сый, – диде оешманың җитештерү буенча идарәчесе Илсинә Минһаҗева.

Аның сүзләренчә, баштагы мәлләрдә егет белән кыз барысын да үзләре эшли. Хәзер исә җитештерү өчен Илсинә җаваплы булса, реклама, финанс мәсьәләләрен Ильяс хәл итә. Шунысы сокландыра: яшьләрне бизнестагы авырлыклар да, җаваплылык та куркытмаган. Сүз уңаеннан, Илсинәгә – нибары 23 яшь.

– Эш тә, яхшы хезмәт хакы да бар, уңайлы график та тәкъдим итәбез, ләкин эшләргә кеше табу авыр, – ди ул. – Яшьләрнең карашы Казанга төбәлгән. Калганнары эштән һәм җаваплылыктан курка. Мин үзем кечкенәдән үк эшләп үстем, шуңа күрә эшләргә теләмәгән кешеләрне аңламыйм. Шул ук вакытта үзләре теләгән эш булса, Арчада калырга каршы булмаучылар да бар. Шуңа күрә үзебезнең дә киләчәктә төрле эш урыннарын арттырасыбыз килә. Минем дә Казанда калу мөмкинлегем бар иде, тик Арчага кайтуны сайладым. Миңа кешеләр, команда белән эшләү ошый. Аннан соң, тормыш кыйммәтләре безнекенә охшаш булган хезмәткәрләрне сайларга тырышабыз. Безнең өчен эшебезнең һәр баскычында гаделлек, намус һәм эш сөючәнлек кебек сыйфатлар мөһим.

Зөһрә САДЫЙКОВА

Сораштыру

НӘСЕЛ ДӘВАМЧЫЛАРЫ

22 ноябрь Уллар көне буларак билгеләп үтелә. Рәсми көн булып, дәүләт күләмендә бәйрәм ителмәсә дә, балаларга карата булган игътибарны тагын да арттыру өчен менә дигән мөмкинлек бу. Без дә, бәйрәм алдыннан, ир бала тәрбияләүчеләрдән бәгырь җимешләре турында сораштырдык.

«Кирәк җирдә тавыш та күтәрәсең»

Гүзәл ИДРИСОВА,
Татарстанның атказанган артисты (3 малай):

– Мин – бик таләпчән әни. Ир-ат нәрсәдер эшләр өчен хатын-кызны көтеп утырырга тиеш түгел. Иң гадәти нәрсәләрне дә ул үзе башкара белергә тиеш. Шул ук пөхтәлек, чисталык мәсьәләсендә дә: чәч-башлары чиста булсын, вак-төяк киемнәрен үзләре юа белсен. Кирәк икән, ашарга да пешерә белсеннәр, идәнен дә сөртеп алсыннар. Бу тормышта мөстәкыйль булу кирәк. Шуны таләп итәм дә. Олыларга карата ихтирамлы булыгыз, дип өйрәтәбез.

Малайлар гына тәрбияләү, әлбәттә, холкыма тәэсир итә. Тормышка бөтенләй башкача карыйсың. Бәлки, кыз бала үстергән кеше йомшаграктыр. «Мама троих детей – это спецназ» дигән сүз бар бит әле. Мин аның белән бик килешәм. Дөрестән дә, кирәк җирдә тавыш күтәрергә дә туры килә, чөнки ул өч малай сине һәрвакыт ишетеп бетерми.

Малайларымның кечкенәсе миңа охшаган, дип уйлыйм. Белемгә омтыла, бик тыныч, һәр нәрсәне үлчәп, уйлап эшли ул. Олысының чиста-пөхтә булуы – миннән, кыюлыгы – атасыннан. Өйдә тәртип булдырырга ярата. Чисталыкка мөкиббән инде менә! Безне сүгеп тә ала кайчак. Арттан җыештырып та йөри. Уртанчы балабыз хезмәт сөючән. Эшне башлый икән, аны азагына кадәр башкармыйча туктамый. Бу сыйфат та миннәндер. Шук ул. Техника белән кызыксына. Монысы инде әтисеннән киләдер.

«Алар белән дөньяга ир-егетләрчә карарга өйрәнәм»

Гөлүсә БАТТАЛОВА, шагыйрә
(3 бала: бер кыз, ике малай):

– Улларымны бик яратам, аларның үсешенә кулымнан килгәнчә ярдәм итәргә тырышам. Шул ук вакытта кайбер урыннарда шактый таләпчәнмен дә кебек. Улларымның серләрен саклардай, уртаклашасы килгән сүзләрен тыңлардай әни булырга омтылам. Һәр хәлдә, үземне шулай итеп тәрбиялим.

Малайлар үстерү холкыма тәэсир итмәде. Ир балаларның үсешен, үзгәрүләрен күзәтү кызык. Аларның дөньяга карашы да, дөньяны танып белүләре дә башка төрле. Аллаһы Тәгаләгә шундый балалар биргәне өчен рәхмәтлемен! Алар белән бергә дөньяга ир-егетләрчә карарга өйрәнәм.

Холык буенча иремнән дә, миннән дә күпмедер дәрәҗәдә барлык сыйфатларны җыйган алар. Иң матурларын, иң күркәмнәрен алганнардыр дип өметләнәм инде. Үзеңнең, иреңнең билгеле бер чалымнарын балаларда күрү – могҗиза. Алар, бездән туган булсалар да, аерым бер кеше, мөстәкыйль шәхес, алар үз язмышын яши.

«Улыма дус булырга тырышам»

Фәнил ВӘККАЗОВ, алып баручы
(2 бала: бер кыз, бер малай):

– Мин улыма дус булырга тырышам, дисәк, дөрес булыр. Үземнең таләпләрем дә бар инде, әлбәттә. Үз фикере булуын, куркак булмавын, чиста-пөхтә булуын телим.

Һәр әти-әни балаларының идеаль булуын тели, ләкин аларның кеше икәнлеген онытырга ярамый. Ә кеше идеаль булмый. Бала туганда ук үз әти-әнисенең уңай якларын да, начарларын да үзенә туплыйдыр, дип уйлыйм. Бу сыйфатлар аңа дөньяга яраклашырга, яшәргә ярдәм итә ала икән, димәк, барысы да яхшы.

Әти-әнинең миңа «син тегенди бул, син мондый бул» дип әйтеп утырганын хәтерләмим. Аларның моңа вакыты да булмагандыр. Мин яхшы укырга теләдем, спортка һәм иҗатка тартылдым, җиңелергә яратмадым. Менә шундый булып туганмын чөнки. Шуңа мин үз улымнан да әллә нәрсәләр таләп итмим. Ул үзе нинди булып туган, шундый булачак. Киләчәк күрсәтер. Иң мөһиме, гомере озын булсын һәм үкенечле булмасын. Ә миңа исә балаларымны нинди бар, шундый итеп яратырга гына кала.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

Баш мөхәррирнең беренче урынбасары – ХӨСНУЛЛИН Илнар Хәлил улы
Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ,
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ АППАРАТЫ
Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2023 елның 23 августында теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – ПИ № ТУ16-01758.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.
Тираж – 5159 данә
Гомуми тираж – 13584 данә
Газетага сертификат бирелде
Заказ 355

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага өч тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.
Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты (420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).
16+